# УЛ ИКЕЛӘНӘ ИДЕ

## 1

Әллә ничек уйламаганда килеп чыкты. Хәмит әфәнденең урамда очраткан дусты, әллә кайлардан үтеп, сүзне шул мәсьәләгә китереп тоттырды. Хәмит әфәнденең мәҗлестә очраган таныш аш-су, кадер-хөрмәттән соңгы сүзләренең замирын шуңарга кайтарды. Әтисенең өстенә Коръән укырга алып барган хәзрәт тә, юлы чыккач шул сүзгә кереште. Көн буе эшли-эшли арып бетеп, аулакта гына дуст-иш берлә утырганда да шул мәсьәлә мөзакәрәгә куелмый калмады.

Хәмит әфәнденең бөтен тирә-юне шул мәсьәлә белән капланды. Карт тутасы: «Әле менә яңа күлмәк тектердем, җизнәң: хәмит өйләнеп китсә, хәзерлексезлек булмасын [диде]» — дип, күзләрен тутырып карады. Әнисенең ахирәте Миңнесафа абыстай да «күреп чыгыйм» дип кергәндә Әхмәди абзыйның Гарифәсенең матурлыгын, зифалыгын сөйләргә онытмады. Дусты Әхмәтҗанның Хәмиттән качмый, аны агай-эне итеп танырга өйрәнгән Мәхфузә дә чәй янында, аш артында әле Фатыйманың зифалыгын, әле Гайшәнең матурлыгын, әле Әсманың байлыгын сөйләүдән туктамады. Әллә ни булды... Әллә бөтен дуст-иш иттифак итештеләрме?.. Әллә үзеннән-үзе чыкты. Хәмит әфәнде килү белән өйләнү, кыз табу, хатын алу мәсьәләсе ачылды. Хәзер бөтен кешеләр берсе артыннан берсе Зөһрәне, Наҗияне, Гафифәне мактарга керештеләр. Ирләр үзләре генә калдымы, гаилә хәятының вакларын җентекләргә тотындылар. Шунысы гаҗәп, хатыннан рәхәт йөзе күрми торган Фазылҗан да, хатынының холыксызлыгыннан бер аерып, бер алып, талакның актык очына килеп йиткән Бәдри дә гаилә хәятын мактауда түти аяклы Фәхретдиннән артка калмыйлар иде. Бу сүзләр һәрвакыт бер кешегә табынылып сөйләнмәсә дә, шундагылар әллә нигә Хәмиткә карашалар, әллә нигә шул сүзләр аның тоткан урыны, аның хезмәте, гаилә арасындагы йөреме хакында уйлашулар уята иде. Иң кызыгы шул: бер кыз макталына башладымы, ни төрле булса да гаилә хәяты бизәкләнелә башладымы, Хәмит

әфәнде әллә нинди бер тойгы белән шул сүзләр, шул фәлсәфәләр үзе өчен икәнен сизә башлый, күп вакытта абайламаенча: «Юк ла, сез алай дисез дә, ул бит минем өчен яшь булыр»,— дигән кебек сүзләр белән үзенең уены тышка чыгара иде. Көннәр үткән саен шул кыз алу, өйләнү мәсьәләсе ачыла-ачыла, Хәмит әфәндене өйләндерү булып, ап-ачык булып алга килеп басты. Тагы әллә ничек, бер дә уйламаганда дуст-иш белән гөрләшеп сөйләп утырганда Закир тотты да: «Әйдәңез, дустлар, Хәмитне өйләндерәмез, нәрсә дуадак каз кебек йөри»,—диде. Бөтен мәҗлес бердән гөрләп каршы алды, өй хуҗасы Гайшә абыстай: «Күптән, күптән вакыт»,— дияргә өлгермәде, Хәйренниса да: «Мин җаучы булам, әнә беләсезме, Хәмит әфәнде, теге кызга?» — диде. Хәмит иренеп кенә елмаеп кызарды.

Шундый вакытта сөйләнә торган: «Минем әле бетерәсе эшләрем бар. Менә урынлашып йитим әле, әле бит урынга керүемә күп түгел»,— диергә өлгермәде, кемне димләү, кемгә сүз салу вә кемне алу мәсьәләсе мөзакәрәгә куелды. Хәмит әфәнде әллә ни әйтергә теләсә дә вә әллә никадәр озын сүзләр белән үзенең өйләнергә нияте юклыгын бәян итсә дә, аның сүзенә әһәмият биргәне дә, тыңлаганы да булмады. Шунысы кызык, ул үзе дә шул үзеннән башка, үзеннән сорамаенча үзен өйләндерү мәсьәләсе сөйләнгәнгә протест итмәде. Бик каты иттереп: «Җәмәгать, өйләнү, кыз алу — һәр кешенең үз эше, шәхси эше, аңарга катышырга ярамый. Сез минем никадәр дустларым булсаңыз да сезгә ул хакны мин биргәнем юк. Вә мәсләкем буенча бирә дә алмыйм»,— димәкче булды. Ләкин, әйтә башлагач, әллә ник бөтенләй башкача булып чыкты. Ул, ни өчендер, шундагы ханымнарга илтифатлары өчен рәхмәт укып, татар хатынының олуглыгы, уңганлыгы, гаилә тормышы ясауда булдыклылыгы хакында сөйләде. Шуннан соң бик оста иттереп, бик шома иттереп: «Ханымнар, әфәнделәр, һәр кешенең үзенең яратканы бар, һәркемнең үзенең сөйгән, сөймәгән холыклары, төсләре бар, шуны белмәенчә кешенең гомерендә бер генә мәртәбә була торган шул мөкаддәс эшкә сез ничек оялмаенча катышасыз, мин —Хәмиткә, дөньяда шактый гына күп хатын-кыз күргән Хәмиткә ничек иттереп оялмаенча әллә кемнәрне димләргә

батырчылык кыласыз»,—диергә булды. Ләкин ул сүзләр урынына әллә нигә ул: «Төс-буе күңелгә тулса, гакылы, холкы табигатькә охшаса, рәхмәт инде»,— дип бетерде. Иң ахырдан шундагы ирләр вә хатыннар белән мәйданга исемнәре ташланылган кызларны җентекләргә, буйларын, төсләрен, холыкларын, укышларын сорашырга кереште. Иң соңга таба әллә ничә кешене өйләндереп, әллә ничә кызны бәхетсез иткән, әллә ничә егетне үзенә ошамаган хатынлы ясаган Зөләйха абыстай белән генә дә әллә никадәр аерым да сөйләшеп утырды. Мәҗлестән чыгып, бөтен кунаклар белән күрешеп үз өенә таба борылгач, моңлы ай яктысы астында уйга калды. Аның күңеленә: «Мин нишләдем? Тилердемме әллә?» — дигән фикер кереп утырды. Ул бердән көлеп җибәреп: «Яхшы ахмаклаттыммы тегеләрне? Бөтен кичне шул кирәкмәгәнгә үземә кыз эзләтеп вакытларын әрәм иттердем»,— диде. Ләкин көлүенең уртасына җиткәндә генә әллә нинди эчтәге бер куәт туктатты. Тагы көләргә тырышса да, тегеләрне ахмаклаттым, дигән фикерне озайтырга, сузарга, ботаклаштырырга теләсә дә, күңелнең әллә нисе аның уен көлке сукмагыннан читкә алып китте. Әллә ни булды, әллә ни эшләнде. Әллә нинди зур бернәрсә җимерелде. Әллә ни туды, башка, йөрәккә көтелмәгән бер икеләнү, бер курку кереп яшеренде. Тора торган йортына кайтып җиткәч тә, бормалы-бормалы караңгы баскычларны менгәч тә, мышный-пошный читкә таба киткән ишек ачучы юан асрау марҗаны күргәч тә, аның күңеленнән шул әллә нинди бер хис китмәде. Өйдән чыкканда Хәмит булып киткән Хәмит, кайтканда әллә нәрсә тагып ияртеп кайттымы, әллә нәрсәсен онытып калдырып, югалтып кайттымы — үзгә төсле булып килеп керде.

## II

Үзенең куйган урыныннан акыртын гына алып, шырпы кабызып ут яккач та, аңарда шул әллә нилек бетмәде. Ялкау гына яна торган лампаның яктысында ул үзен карар өчен, үзендә үзе нәрсәсе югалган, нәрсәсе артканын күрер өчен көзгегә күзен ташламакчы булды. Көн дә биш вакыт намаз укырга өйрәнеп беткән мулла хатынының карамаенча-нитмәенчә туп-тугры иттереп

кыйблага таба йөзен юнәлдерүе кебек, өйрәнеп беткән көзгегә күзен ыргытты. Ләкин, әллә нигә аның күзе читләп китеп, элек көзгенең астындагы бер кара тапка, аннан соң бүлмәнең кәгазенә төште. Хәмит әфәнденең бүлмәсенең кәгазе карасу-кызыл, акайган бизәкле икән ләбаса. Әй ул бизәк тагы таныш та, ул менә шул ук бизәкне әллә кая гына күрде. Әй, хәзер әйтә... Тел очында гына тора. Шкаф янындагы этажерка?.. Бу монда кайдан килгән? Китаплары моныкы, әнә русчалар, әнә нечкә-нечкә татарчалар. Барысы да Хәмитнеке... Этажерка? Чын, кайдан? Әллә бар идеме? Юк, ул бит әле көзгегә карамакчы иде. Көзгегә бик озак текәп карады. Юк, бер үзгәреш юк. Чигәләрдә ак чәчләр генә аз гына ялтырый, кара чәч арасында ул көмешләнеп зиннәт кенә бирә бит. Битендә кечкенә генә җыерчыклар булгалый башлаганмы? Юк, ул тик әле соңга калып кайтканга гына. Тагы, көзге дә бит шәп түгел. Лампа да начар яна. Иртәгә Марфага әйтеп фитильне кистерергә кирәк. Юк әле, Хәмит әфәнде тәмам җиләк кебек. Дөрест, утыз ике яшь аз түгел, күп тә түгел. Инглизләр бит 35 кә йитмәгән кешегә өйләнергә ярарлык дип карый да алмыйлар, ди. Хәмит әфәнденең тормышы, әлбәттә, бик шәп үк булмады, бик үк шома үтмәде. Алай да зарланырлык түгел.

Кулындагы ак куллыгын акыртын гына алып өстәлгә куйды. Ак куллык янында өстәл өстендәге таплы ашъяулык оялып китте. Ул шуны оялтмас өчен кебек акыртын гына муен бавын тишеп, чәбелтеп ыргытты. Яканы алып, этажерканың баганасына эләктереп куйды. Сәгатене ычкындырып караваты янына элде. Караватында әллә нинди яңалык күрергә теләгән кебек, үткен күзе белән аны сөзде. Мендәре, мендәренең төймәсе төшкән ак тыш астыннан акаеп тора торган зур бизәкле тышы ыржаеп, мыскыл итеп көлгән кебек булды. Аның әллә нәрсәгә ачуы килде. Тиз генә чалбарының элмәләрене җибәреп, төймә урынына кадаган английский булавкаларын алып салып ыргытты. Эчне пошыра торган нәрсә менә шул икән, дигән кебек иттереп ачуланыбрак ыргытты. Аяктагы ботинкаларның чыкмый торган бауларын тартып-өзеп салышып ташлады. Юрганны ачып сузылып ятты. Ләкин тагы әллә ни тулмаган, әллә нәрсәсе артык, дигән хис басты. Әллә нәрсәне көтү берлә әллә

нәрсәсе китүне кызганудан мөрәккәб бер тойгы килеп чыкты. Анының күзе бүлмәдә йөгереп шул әллә нәрсәне, шул үзгәрүнең сәбәбен эзләргә тотынды. Кеше күрми,үзгәрү белми айлар, еллар бер бүлмәдә төрмәдә яткан кешенең һәр ноктасы мәгълүм бүлмә диварларыннан үзгәлек, башкалык эзләве кебек, бер күреп чыгуда тапмаса да, тагы-тагы җентекләве кебек, Хәмит тә бөтен түшәмне күздән үткәрде. Түшәмнең тактасымы? Унбиш икән. Парлап санасаң, бу якта берсе так кала. Аңарга матчаны кушсаң?!

Әнә теге җиденче такта ул кадәр киң булмаса, уналты кирәк булыр иде дә, бар да парлы-парлы булыр иде. Булмаса, ни була?

Менә юк уй. Чын да, әллә теге хатыннар, ирләрнең сүзе дөрестме? Өйләнергәме? Мәсәлән, ул шул шәһәрнең Фатыйманы алса?.. Әйе, Фатыйма бунының хатыны булса?... Төсе-буе.. Зарарсыз...

Әллә Хәдичәнеме? Хәдичә моның хатыны булып, шулай менә бүген Габдерахманнарда булган кебек, хуҗа булып, кунаклар каршы алырмы?.. Бер-бер нәрсә җитмәсә, моның колагына гына әйтеп, акча алып, ябык кибетне ачтырып китерергә асрауны җибәрерме?..

Бар да юк сүз. Кеше соң үзенең хөррияте шәхсиясен бетереп, шулкадәр яшьли өйләнәме?..

Тукта, әле хезмәт тә алгарак китсен, банкада тагы берәр дәрәҗә үрләсен, жалование ике йөзгә йитсен... Аннан ары. Аннан тагы ничек сөймәенчә өйләнергә? Сөяргә ничек, кайвакыт, кемне, кайда? Менә утыз ике яшькә җитте. Тилереп ахмак булырлык бер кеше очрамады. Очрамаса, очрар... Табигать бит кешеләрне так яратмый? Кая булса да минем сөячәк, яратачак бер кызым, бер хатыным бар. Ие, бар шул... Ул Америкада, анасы инглиз, атасы итальян булган бер гаиләдән туган кыз булса?.. Ул үзенең сөйгәнен үтергән өчен каторга киткән бер никә булса?.. Булса... Әйе, фараз күп, баштан юкны чыгарырга кирәк.

Ул өйләнде... Тагы, тегеләрне ахмаклаттым бит, дип көлмәкче вә бөтен шул чуалчык уйларга тыныш куй-макчы булды. Тагы көлке яртысында өзелде.

# III

Крантның пыт-пыт моңлы тавышына кушылган ишекнең озын гына шыгырдавы Хәмит әфәнденең күзен ачтырды.

Ул иркәләнеп сәлберәеп ятмаенча бердән уянды. Кичә генә бер беренче мәртәбә күргән кәгазьләр, дивар тапларын карарга өлгермәде, аның борынына әллә нинди бер ис керде. Борынының әллә кайбер җире кечкенә генә хушбуй ис сизенгән кебек булды, бер йире яңа пешкән икмәкме, бәлешме исе тойган кебек булды, әллә нинди бер йиренә, зур кәнфит кибетләре янында борынга бәреләә торган бер җил сугылган кебек булды, әллә кайбер җиренә, озак авыру яткан бүлмәдә генә очрый торган иске мәдрәсә һавасы тоелган кебек булды. Шул исләрне иҗеклэп торырга өлгерә алмады, күрше бүлмәдәге хуҗа хатынының көйләп-сөйләп баласын чүп-чүп үпкәне аның дикъкатен үзенә борды. Күршедәге сүз, үбү, сөю күбәйгән саен ул шул уйга чума барды. Менә таза гына, пычрак кына хуҗа хатыны, ямьсез генә, симез генә баланы кулына алган да, сөеп маташа. Анын күзендә нур уйный, йөзе көлә, теле дөньядагы әйтмәгән матур сүзне калдырмый... Әйтерсең лә бәхет кошы тоткан. Озакламас, шул бала дөньядагы бөтен ямьсез тавышларны бергә кушып акырырга тотыныр. Ул вакытта ул аны тагы ямьсез сүзләр белән тиргәргә керешер. Юк шул, менә шул хатын, бала никадәр кылынса да тиргәми, авырсынмый, кыйнамый, орышса, сүз әйтсә, асрауларны гына шелтәли, тирги. Әйе, бала шул, безнең әни: «Үз балаңыз булгач белерсез әле»,— дия иде. Беләсе юк, бик мәгълүм. Бала мәгълүм вакытта туа, мәгълүм айлар сөт имә, мәгълүм елларда үсә, шуннан соң кеше булып, дөньяга чыга...

Ул үзен шул мәгънәсен мантыйкта тоттымы, әллә нәрсәгә каршы бер хыянәт ясаган кебек кызарып китте: «Чү, җитте! Мин әллә нәрсә ахмак уйлар уйлый башладым»,—диде дә акыртын гына торып утырды.

Күзе йонлы кулыннан йөгереп аяк тырнагына барып туктады. «Күптән кисәргә вакыт. Иртәгәдән калдырырга ярамый». Оекны кулга алгач, башына килгән зур мәсьәләне хәл итә алмаенча катып калды. «Күлмәк-ыштанны алыштырыргамы, түгелме?» Алай карады, болай карады. Алыштыру-

алыштырмау хакындагы дәлилләр бер-берсе белән бәрелешә, сугыша башладылар. Бер вакытта алыштыру җиңәр кебек булды, берсендә кичектерү мәслихәтлеге басар кебек тоелды.Тагы үзен шул ахмак моназарәдә тотып, тиз генә сикереп торып юынырга кереште. Талгын гына су тамчысы кытыклап, күкрәк буйлап агып китте. Шуның котны алмавыннан батыраеп киткән кебек булып, ул суны учлап-учлап алып муеннарын юарга кереште. Чәчләрендә, битләрендә су тамчылары кая барырга белмәенчә аптырап торганда, мыегы янына җыелган су бөртекләре, бергәләшеп агып төшәр өчен киңәш итешкәндә, ул, тастымал алып, сөртенер өчен көзге янына барып басты. Башка вакытка караганда озаграк, җентекләбрәк ул көзгегә күзен текәде. Битендәге суларны сөрткән саен бер мәртәбә карап алды. Кызарып киткән бите, ап-ачык муены, бер ябышып, бер кубып тора торган юеш күлмәк астындагы күкрәге Хәмиткә бәбәген акайтып карады. Ул уйлаган уеның җебене югалтып тик торганның соңында: «Әйе, юк әле, карт түгел»,— дип куйды. Шул уй аны батыр иттеме, шул уй аны чынлап та яшәштеме, ул тиз-тиз генә юеш күлмәген салып ыргытып, комодка тыгылды. Тәненнән йөгергән суык һаваның кытыклавыннан котылыр өчен тиз генә күлмәкне алып киде. Кулларында әллә нинди көч хис итеп, аларны бутап куйды. Уйламаенча гына каптырмаларга кулын борды. Русча тегелгән күлмәкнең төбеннән алып якасына кадәре бер төймәсе юклыгы Хәмит әфәнденең бөтен уен башкага борды. Бөтен кәефен бозды. Ул комодтан икенче күлмәкне алып кимәкче булды. Өченчесен алып карап чыкты, дүртенчесен күздән сөзде. Берсендә дә сәдәф — каптырманың эзе дә юк...

Менә, шул, ни өчен безнең бабайлар баулы күлмәк кигәннәр икән!

Менә хәзер инде нишлисең?

Ул үзенең ак якага дигән запонкаларын берсен эләктерер өчен күлмәкнең якасына пәке очыны тыкты, икенче ягына эләктерер өчен тагы бер тишек уйды, ләкин никадәр эләктерсә дә, төймә тормаганга аптырап калды. Ул: «Шуларның һәммәсен асраучы әйтеп төймә тактырырга кирәк»,— дигән карарга кырыгынчы мәртәбә килде, аннан-моннан тапкан төймәләрне кара җеп

белән кадап кигәч тә шул ук карарын кырык беренче мәртәбә дә онытты. Оектагы тишекләрне күргәч, ул һичбер төрле үз куәте, үз гыйлеме, үз тәҗрибәсе белән генә хәл ителәчәк мәсьәләгә очрамаган икәнен сизенеп, бу көнгә генә кара оегыны кияргә булды. Вә шул төрлесе төрле төстәге үзенең парларын югалтып бетергән оекларга карап, аларны да тутыгыргамы шунда, тектерергәме, хасыйле, шул оек мәсьәләсен хәл итәргә сүз беркетте.

Якалар, күкрәкләр, куллыклар эчне пошырмаганга, биш минуттан Хәмит әфәнде тәмам хәзер булып. Акыртын гына ишекне ачып: «Маша!» — дип кычкырды. Шул кычкыруны хуҗа хатыны да, асрау да хәерченең сәламе кебек иттереп «мин тордым» дигән мәгънәдә аңларга өйрәнгәгә, озак үтмәде, асрау поднос күгәреп килеп керде. Каралуны белми торган ашъяулыкны алып селкеп, подносны куйды, тәрилкә белән майны, булкины читкә төртте, иртәнге гәзитәне Хәмит әфәндегә сузды.

***

Хәмит әфәнде телеграммалар карарга өлгермәде, моң гына җырлый торган самавыр керде. Хәмит әфәнде тәҗрибә белән самавырның бөтен телене белеп бетергәнгә, бу җырлаудан: «Озакламыйм, сүнәм, озакламыйм, үләм»,— дигән мәгънәне ишетеп, тиз генә чәй пешерде. Самавырның бердән җырлаудан туктавы аңарга әллә нинди итеп тәэсир итте. Менә кичәге кебек ул бердән үзенең бөтен чәй яныны күрде. Менә таплы, айда бер алыша торган ашъяулык, менә сөртмәгән самавыр, менә борыны китек чәйнек, менә көн дә бирелә торган пыяла астлы стакан. Аннан ары чирек май, булки, өч ел элек алган чәй савыты, шикәр капчыгы ... Һәммәсе гүя шул урынга катканнар да торалар. Гүя һәммәсе дә бетмәскә булып килгәннәр дә моның өстәленә утырганнар... Кайчан ул шундый өстәлне күргән иде? Валлаһи, күргән иде. Кайчан соң? Менә хәзер хәтерли...

Ә тапты, менә шул шәһәргә килеп, шул бүлмәне алган көнне... Аңарга инде, әфәндем хәзрәтләре, ике ел да өч ай да егерме бер көн булды... Шулай... шулай ...

Шул бертөрлелек, шул берсенә берсе охшаган көн үткәрү аның әллә кай йирене өшетте, әллә нәрсәсене әрнетте, әллә нәрсәне кызгандырды. Ул озак итеп катып торганның соңында: «Йитге, туйдым!» — диде. Шул сүзләрдән үзе дә курыккан кебек булып китеп, искөртмәстән торып йөрергә тотынды. Башындагы уй тулкыннары берсе артыннан берсе килеп әүвәлгеләрен юып киткәнгә, тулкыннарны куып йитәр өчен кебек кызу- кызу атларга кереште. Уйдан уйга чума-чума стаканы суынганын, самавыр сүнгәнен онытты, сәгать үткәнне, хезмәткә барырга вакыт йиткәнне дә хәтеренә китерә алмады. Бөтен көче, куәте белән: «Берни дә булмады. Бүген кичә төсле. Иртәгә бүгенге төсле»,— дигән уйны башына тукыса да, күңеленең әллә кай йирендә яшеренгән, сакланган: «Туйдым бу тормыштан!» — дигән фикер аның тынычлыгын кимергәннән кимерде. Аның күңеленең бер кырыенда үзгәрү, башкару теләү уе, бәрәкәтле ягъмур астында калган үлән кебек вә сәдидә үсте. Ул кызуланып хезмәткә китте. Юлда шул фикерне башыннан ыргытыр өчен сәясәттән уйларга кереште. Мәсәлән, Балкан иттифакы кебек, Африкада иттифак булса... Мисыр, Судан, Фасен, тагы әллә кемнәр иттифак ясаса... Әйе, шуннан. Австралия аталарында бер инженер, су астыннан очып йөри торган яңа аэроплан ясауны кәшеф итә...

Ишек ачучының баш июе аны уятып йибәрде. Ул тиз генә киемнәрен салып кызуланып китмәкче булса да әллә нәрсәгә көзгегә борылып чәчләрен төзәтте. Мыегын сыпырды, киемендәге бер йон кебек нәрсәне алып ташлап, акрын гына урынына таба бара башлады. Үзеннән кечкенәләргә баш иде, зурларга, иптәшләргә кул биреп, урынына утырырга өлгермәде, сары башлы маржа килеп: «Хәмит Вахидич,—дип көлеп-көлеп сөйләргә вә ридикюленнән чыгарып: «Биримме, ни бирәсез,—дип?» хиссиятләнергә тотынды. Хәмит әфәнде шул марҗаның озын гына, ак кына йөзенә, тирән генә, зур гына күзләренә, матур булмаса да сөйкемле генә күренешенә, зурайтып, күләмләп тора торган бай саргылт чәчләренә карап аптырап калды. Ул шул марҗада, аның шул елмаюында, аның шул иелеп-бөгелеп сөйләвендә, кылынуында үзенең әллә кайчан эзли торган әллә нинди бик кадерле, бик кирәкле бер нәрсәсен

тапкан кебек булды. Ул марҗаның сүзләрен дә тыңламаенча: «Мин шул марҗага өйләнәм»,— дип куйды. Бердән, өйләнергә теләвен үз алдында үзе икърар итүе, икенчедән, марҗага өйләнергә дип төшенүе шулкадәр ят булды, ул кызарды. Марҗа аның кызарганын күреп: «Ә менә шулай, ах, сез рәхмәт тә әйтә белмисез. Мин мәшәкатьләндем, йөдәдем, көчкә таптым, сез кайгырып утырасыз. Алай булса, мин бирмим!»,—диде. Хәмит: «Юк, Мария Ивановна, валлаһи шулай, болай...» — дип, марҗага театрга билет китерүе өчен бик рәхмәт укыганын, аның шул хезмәтен кыяматкә кадәр онытмаячагын сөйләп, Мария Ивановна белән кайда күрешү хакында сүз беркетте.

Театрда икәү бергә утырганда Мария Ивановнаның матур гына, йомшак кына профиле, Наташаның җырлаган вакытларында аның авыр-авыр сулап тыңлап торулары, антракт араларында театр, музыка, әдәбият хакында бик үк төпле гакыллы мәгълүмат сатмаса да, йомшак кына, җылы гына, матур гына сүзләр сөйләүләре дә аның башында баягы «чын да шуңарга өйләнсәң?» дигән уйны үстергәннән үстерә барды. Чын да, нинди һәйбәт, инсафлы, мәхәббәтле кыз. Тагы шундыйны кайдан табарсың?.. Бу баланы шулай «үт-үт» иттереп сөя беләчәк...

Бу да ире кайтканны дүрт күз белән көтеп торып, иренә ярар өчен бөтен авырлыкны күтәрәчәк... Бу да күлмәкләргә төймәләр тагачак... Оекларга табаннар бәйләячәк... Монысы бигрәк ваклык, мин соң хатынны хезмәтче иттереп аламмыни! Мин иптәш, юлдаш иттереп алам... Мария Ивановна юлдаш, иптәш булмыймыни?..

Ул бит инде, Хәмит булса да, шактый шомарган, шактый үзгәргән, кыскасы гына шактый урыслашкан. Ул инде марҗа белән торыр дәрәҗәсендә образованныйлашкан...

Җомга көн иртә белән ул пәрәмәч китерерме?.. Гарәфә көнне ул бәйрәм ашы ясый белерме?.. Татар театры килгәндә, ул шуннан бернәрсә аңлый алырмы?.. Ул шул уйларны бердән өзеп ташламакчы булды. Үзенә-үзе бик нык иттереп: «Әфәндем, әле без өйләнергә уйламадык. Ул вакытта Фатыймамы, Гайшәме, Марияммы, Аннамы — алар күрелер»,— диде. Ләкин

шул сүзгә үзе дә ышанмаганга, башта тулган фикер тегермән кебек әйләнүдән туктамады. Мария Ивановна белән театрдан соң ужинга студентлар, курсисткалар йөри торган ресторанда ашаганда да күңеленә шул уй утырганнан утыра барды. Ул шул уй белән ияләшеп, шул уйны ботакландырырга, тармакландырырга кереште. Мәсәлән, ул өйләнде, ди. Дуст-ише аны тәбрикләп килә... Килмәсә? .. Бу бит марҗага өйләнү... Кардәш-кабилә... Нинди туй? Марҗа белән туй буламыни?.. Тагы алар берсе дә килмәсә? Килмәсә генә түгел, моның өйләнүене өйләнү дип карамаенча, тик марҗа белән тору гына, тәүфыйксызлыктан килгән бер бәхетсезлек кенә дип караса?..

Аларның алай карарга ни хакы бар! Сөю, мәхәббәт милләтне белми. Аңарга байлык, ярлылык киртә-кальга була алмаган кебек, милләт, дин аермасы да аны тотып кала алмый. Мин сөйгәч кемнең хакы бар! Ләкин бит мин сөймим, мин бит гакыл белән өйләнергә йөрим, йөрмәсәм дә шул гакыл белән өйләнү алдында торам.

Читтән генә бер кешенең баш июе аны уятып җибәрде. Менә бу кеше, Хәмитне банкада да, җәмгыяте хәйрия җыелышларында да танучы «шул яшь фикерле бай» хәзер ни дип уйлый? Хәмит берне эләктергән бит, ди, шул...

***

Мария Ивановнаны өйгә озатып күрешкәндә дә баягы бераз чуалчык уйлар баштан әрчелмәде, Марияның күрешкәндә кулын кысып күрешеп, сые өчен рәхмәт укуы күңелендә тагы әллә нинди уйлар, шөбһәләр уятты. Ул: «Йә, ярый, шулай, ди. Мин моны сөймим, бу марҗа кызны. Ләкин соң мин шул үземә яраган татар кызын таба аламмы? Күрә аламмы? Сөя аламмы?.. Юк шул. Кайсы өйдә дүрт дивар арасында утыра, кайсы без кул җитмәслек дәрәҗәләрдә йөри... Курсистка, гимназия бетергәннәре безнең кул йитәрлек түгел. Тагы аларны кайдан табасың? Аларга ни сөйлисең... Ни сөйләсәң дә бит ахмаклыктан, наданлыктан сөйли, дип көлдереп тору бик кызык түгел. Хәер, әле өйләнергә бер карар бирсәк, анысы әле уйлашыдыр иде. Мин бит әле өйләнергә карар биргәнем юк...» Урамда кеше булмаудан файдаланып, ул

җөмләләрне кычкырып әйтте. Үзенең күңеленең бер кырыендагы тавышның көчен басар өчен сүзне тәҗвидләп, ап-ачык иттереп әйтте. Вә шуның берлән шул әйләндергән мәсьәләгә хитам бирү өчен каты, ирчә әйтте. Ләкин җөмләнең ахыры әллә нигә зәгыйфь, куәтсез чыкты. Күңеленең теге кырые үзеннән үзе көлгән кебек булды. Өйгә кергәч тә бу юлы утны кабызмаенча гына тишенеп ятты.

## IV

Хәмитнең иң беренче хисе авызының авыз түгеллеге булды, әллә аны утыннан ясап куйганнар, әллә аның урынына кеше авызын китереп ясап утыртканнар. Аның теле, сөйли-җырлый торган теле туңганмы, катканмы? Аның аңкавы сыланган ярлы мужик өе кебек, әллә нәрсә берлән ябыштырылганмы, әллә шунда аның бөтен тирә-юненә үләннәрме дим, гөмбәләрме дим, үскәнме? Тагы йитмәсә әллә нинди бер тәм — күкфарас тәме белән тимер тәменнән, ак әрем тәменнән кушылган тәм. Тел селкенми. Селкенсә, аның әллә кай йиреннән макшыган шалкан тәме, иске щидән кушылган бер тәм килә. Иреннәргә әллә нинди кавыклар ябышкан. Борынының әллә нинди җирләрен яндырып китереп кызу һава ага. Шуларның нәрсә икәнен белеп бетерергә, ни булганын уйларга өлгермәде, аның эче борып-борып авыртырга тотынды. Ул киерелде, сузылды, бөтен тәнен хәрәкәткә китерде. Ләкин һәммә әгъзасында бер әллә ни басканлык, бер авырлык аны басканнан баса барды. Әллә инде аңарга бер карт көбә тимер кигезгәннәр, әллә бөтен өстенә авыр туннар, толыплар ташлаганнар. Тагы шунысы гаҗәп: бөтен әгъзада әллә нинди бер ятлык бар. Аның кулы, көн буе Хәмиткә эш эшли торган, Хәмитнең бөтен теләген, уен һич карышмаенча кыла торган кулы, хәзер әллә кемнең рөхсәтен алмаенча хәрәкәтләнә алмыймы, ялкаулашкан гынамы? Аның аякларын герләр йиргә бастырганмы, әллә күренми торган калын богау чорнап куйганмы, аны урыныннан селкетми. Хәмит: «Юк, мин төш күрдем, мин бастырылам... Минем өстемә албасты пәрие килеп ятты. Әнә ул үзенең авыр йөге белән акыртын гына өстемә ята,

аның резинка кебек йомшак, сыгыла-бөгелә торган тәне әгъзаларның бөгелгән, борылган һәммә йирләрен тутырып баса бара. Аның очлы ике борыны минем борынның тишекләренә тыгыла. Аның кайнар сулышы авызга таба менә. Авыз гына капланмаган. Менә күкрәкне басты. Тукта, ул бит кяфер шәйтан шулай итеп үтермәкче була. Буып. Иман әйтергә ирек бирмәенчә җанны алмакчы була. Тиз-тиз авызга килгәнчә бисмилла әйтим, ул бит, кяфер пәрие, бисмилладан курка... Тагы сул аякның баш бармагын селкетим, ай, ул баскан, үләм, тыным бетә. Әнә үзенең карабогдай саламы яккан авыл миченнән килә торган эссесе белән бөтен йөзене киптерә, яндыра.

Хәмитне әллә нинди кот очу, йөрәк ярылу куркусы басты. Ул ихтыярсыз: «Әни!» — дип кычкырып җибәрде. Шул әче тавыштан уянып киттеме, әгъзаларын селкетеп албастыны кудымы, аның гакылы башына килде. Ул, каты иттереп «уф, уф» дип сулаганның соңында, күккә сикерергә теләгән кебек дөрс-дөрс килә торган йөрәген туктатыр өчен кулын күкрәгенә куйды. Кулында да, күкрәгендә дә әллә нинди үз түгеллек, кешенекелек, артыклык тагы хис итте. Авызындагы шул агач телне йомшартыр өчен, кипкән-куырылган аңкауларны чылатыр өчен, авызындагы шул шәйтан туена ясала торган аракы тәмнәрен бетерер өчен авызын чайкап, су эчмәкче булды. Акыртын гына торып утырды, бөтен тәненнән бик кызулап үтеп бара торган карлыгач очуы кебек тәнен чемердәтеп бер суыклык, бер чиркану узды,юрганын ябына төшеп, янындагы шырпысын кабызып идәнгә басты. Әллә нинди бер суык, моны әллә кайчаннан бирле көтеп тора торган кебек иттереп, бердән Хәмитне кочаклап алды, аның бөтен тәне дер-дер килеп калтырарга кереште, тешләре шакый башлады. Лампаны кабызып, графиндагы суны алып авызын чайкарга кереште, су әллә нигә, авызда йөрсә дә, авызның корысын бетермәде, авызын чылатмады. Ул никадәр авыздагы суны телләре белән төрле якка чайкаса да, ул авыздагы сасы тәмне, тәмсезлекне юмады... Шунысы гаҗәп, ул авызда юешлек хисен бирә алмады, бирмәде. Әллә бу су — су түгелме? Бу әллә авыл кызларының кулларына тага торган пыялалардан ясаган сәйләннәре, ак төймәләре генәме?.. Әллә бу

шундый коры сумы?.. Калтырый-дерелди ул теш арулый торган пумаласы белән авызын пакьләргә кереште, тешләрен юды. Бармагы белән аңкавын ышкыды. Теге ябышканмы, үскәнме нәрсәләр купмады, авызның теге тәме кимемәде. Ул, дер-дер килеп өши башлагач, тагы барып урынына ятты. Аның башы «чаң!» иттереп уларга тотынды. Тәне тагы бер кызулык белән янарга кереште. Эче борырга, әллә нинди тәмнәр белән борырга, кисәргә, бөтен тәне сыкрарга, авыртырга тотынды.

## V

Хәмит үзенең авырый башлаганын хис итте. Аның башына шул фикернең керүе белән күз алдында һич уйламаган бер курку, кот очу басты. Мин авырыйм, мин авырыйм дип, шул уйда терәлә калды. Менә хуҗалар ягыннан сәгать сукты. Хәмитнең уе шуның артыннан барып унҗидене санады, ул да булмады, теге якта ишекләр ачылу, ябылу, Хәмит бүлмәсеннән ерак түгел җирдә кранттан су агызу ишетелде. Шул чит уйлар аның башын озак мәшгуль итә алмады, ул тагы үз авыруына кайтты. Үзен юатыр өчен: «Юк, болай гына, суык кына тигән, үтәр китәр, менә хәзер җиңеләйгән кебек булды. Менә бераз йоклап алыйм»,— дип, күзен йомды. Арка ягыннан керә торган салкын җилне бетерер өчен юрганын аркасына тыкты, күзен чынлап йомды. Йоклаган кебек мышнап карады. Баш, кайнар баш йокыга китмәде дә китмәде. Ул бөтен көчен йокларга сарыф итте. Хыялын шунда борды. Менә аның хезмәттәге иптәше Хәйрулла йоклый, борыныннан сулышы чыкканда аның озын мыеклары акыртын гына селкенә. Әнә Михаил Иванович йоклый... Ул өйләнгәнме, юкмы?.. Әнә тагы берәү йоклый. Ак кына караваттагы кечкенә генә мендәрләр, йомшак кына юрган аны матур гына иттереп каплап алган. Аның саргылт чәче читкә киткән. Батка мендәр аның ак йөзенә, матур гына борынына нинди табигый җирлек булып тора... Кара, аның йөзеннән нинди гөнаһсызлык, пакьлек балкып тора?.. Ул кем соң? Улмы? Ул... ул маржа...

Менә мәдрәсәдә, ул сабак укыган мәдрәсәдә йоклыйлар, әлиф яткан шәкертләр йоклыйлар. Авыр һавада әллә нинди саташалар, җырлыйлар,

сөйли-сөйли йоклыйлар. Мулла абзый, мәдрәсәгә иртә намаздан соң сабакка керә торган мулла абзый да йоклый. Зур түшәккә сузылып яткан да, ике кулыны җибәргән дә мыр-мыр итеп йоклый. Әйе, һәммә кеше, бөтен дөнья йоклый, мин дә йоклыйм, йоклыйм... Йокларга кирәк, йоклыйм... Әй теге парахуттагы кыз, мин урыс булып танышып сөйләшеп йөргәч, икенче көнне минем мөселманлыгымны белгәч тә каютына качып, күренмәгән кыз да йоклыймы?.. Ул да йоклый. Аның начар иттереп русча сөйли торган авызы хәзер ябылган. Аның русларга татарларны мәдәни бер милләт итеп күрсәтер өчен — татар әдәбияты, татар театры, татар музыкасы хакындагы үзенең башындагы хыялы да йоклый... Йоклый шул. Ак кына кулын моңлы йөзенең бер ягына куйган да, майлы бәлешле, коймаклы ис чыга торган өйдә йоклый... Аның теге ике күзе, Тукайның шагыйрьлеге Пушкиннан ким түгеллеге хакында миңа озын нотык сөйләгәннән соң, татарның шагыйрьләре барлыгына бу урысны ышандырдым бит, дип сөенеп, шатлыгыннан нур түгелгән күзләр дә йоклыймы?.. Чыннан да шул нинди кызык булды. Мин ахмак, икенче көнне үземнең татарлыгымны әйтмәсәм, кем белсен, танышлык ни дәрәҗәгә җитмәгән булыр иде... Аның теге ямьсез калфак кигән, ләпшердәгән күлмәк кигән анасымы, тутасымы, безнең татарчалап рәхәтләнеп сөйләшә башлавымызга килеп чыкмаса, кем белсен танышу ни белән тәмам булыр иде! Ул кыз сөйкемле иде, сөемле иде. Аңарда әллә нинди татар кызында булмый торган чаткы, ут бар иде. Әйе, ул мишәр кызы иде. Ул йоклый, мин дә йоклыйм... Көн ачылды, хуҗалар торып бетте. Хәмит йоклый алмады да алмады.

## VI

Гади вакытыннан берәр сәгать соң торып, юыныр-юынмас кына Хәмит чәйгә утыргач, аның кәефе бигүк начар төсле тоелмады. Авызындагы әчеле-төчеле үт тәме бетмәсә дә, башка кургашын эретеп коелганлык хисе кимемәсә дә, тәнгә әллә нәрсә — юеш бака яулыгымы, әллә инде искергән балык маемы

ябыштырылган, сөртелгән тойгысы азаймаса да, Хәмит үзенең көн дә укый торган гәзитәсен укып чәй эчкән кебек булды.

Татар гәзитәсен күзеннән кичерде, хәтта: «Кәефем шактый яхшырды, әллә хезмәткә барыйммы?» — дигән уйга да керде, ләкин аякларда төне-көне таулар үтеп, сулар кичеп, илләр чыккан авыр хис иткәнгә, телефон белән бара алмавыны гына белдерде.

Үзе тагы чәй янына килеп, теге чынаягы бик тәмсез булганга чынаягын чайкап, чәен яңартып тагы берне ясап карады. Чәйдән баягы күкфарас тәме бетмәгәнгә, ул шуның тәмен онытыр өчен көндәге кебек гәзитәдәге яңа бер хәбәргә, кызыклы бер фельетонга чумып, уку арасында гына эчкәләмәкче булды. Ләкин баштагы ми урынына тутырылган салкын кургашын бернәрсә дә аңлатмаганга, күңелдәге үткен хыял шуларны ялгап китеп, кызыклы хикәяләр, вакыйгалар ботакландырмаганга, ул чәйнең тәмсезен оныттыра алмады, аның ямьсез исенә хыял дөньясыннан нәфис бер ис иснәтә алмады. Башы тупас иттереп уйлаганын, күз тирәләре яна башлаганын сизенеп, ул, торып, идән буенда йөрергә тотынды. Бер-ике әйләнмәде, аягында ару, бик чынлап ару хис итеп тагы урынына утырды. Кулына тагы татар гәзитәсен алды. Минск шәһәрендә андагы поляк мөселманнарының шәрык кичәсе булачак икән.

Шәрык кичәсе... Әйе, шәрык кичәсе?.. Ягъни, шул тирәдәге шәһәрләрдән, авыллардан, утарлардан мөселман егетләре, мөселман кызлары, мөселман хатыннары җыелачак, уйнаячак, бииячәк,бер-берсе белән танышачак. Кызлары егетләргә ошарга тырышачак, егетләре кызларның дикъкатьләрен үзенә борыр өчен төрле егетлекләр эшләргә маташачак. Шунда танышылачак, белешеләчәк, берсе берсенә ошаячак, ярашачак, аннан, Алла насыйп итсә, сөенәчәк, сөеләчәк... Өйләнешәчәк.

Әйе, шулайдыр. Аларның шул кичәләренә өйләнәчәк әллә никадәр егет җыела, ди, кияүгә чыгарга вакыты җиткән әллә никадәр кыз бара, ди. Шуннан соң, бер-ике ай вакыт җитми, яз айлары кереп өлгерми, туйлар китәдер, ди. Прапорщик Соломон Яковлевич Роза Измайловнага предложение ясыйдыр,

телеграфта хезмәт итүче Баязид Давыдович Фатыйма Александровнага өйләнәдер, ди, корнет Мостафа Исакович полковник Сули-ковичның институт бетергән гашыйк Алена берлән качып китәдер, ди.

Вә шул хәбәрләр, вакыйгалар шуларның вак-төякләре, гайбәтләре елга кадәр сөйләргә карт абыстайларга азык була, аларның эчләре пошканда күңел юатачак бер хикәя буладыр, ди.

Кайвакыт шул кичәләргә Бакуның нефтьчесе килеп капитан кызы Марияны алып китә, Казанның сабынчысы генерал кызы Зөләйхага сүз салып, мәсхәрә буладыр, ди. Әллә мин дә шунда барыйммы?.. Ул бит Литва мөселманнары инде йөрүдә, торуда, укуда бездән алда!.. Бәлки шунда бер сөеклесе генә бардыр?.. Әйе, сюртук бар... Кием-салым бар... Үземне үзем аларга яраттырырлык итеп тота белерменме соң?..

Танцевать итәргә?.. Ул үзен үзе тәҗрибә итәргә теләгән кебек, торып, туп-тугры басты. Аягының әллә кай җире калтырарга тотынды. Өстенә әллә нинди зур бер йөк асылганны хис итте.

## VII

«Йә, юкны уйлыйм, мин бит авыру, өйләнү әле кайда, авырып китсәң?.. Тиф булса? Тир хәстәсе булса?.. Шуннан чахоткага күчсә?.. Юк, мин танцевать тә итә алмам. Аннан, без мөселман егетләре мөселман кызлары белән бер-беремезне тота да белмимез. Кечкенә генә бер сүз әйтсәң, артык булыр төсле күренә дә, күңелдә булганны да әйтмәенчә каласың. Кызлар аны «илтифат итмәде» дип каршы алалар. Кечкенә генә бер сүзне бер генә илле, менә кәгазь калынлыгы итеп әйтсәң, иртәгесен бөтен дуст-ишкә, кардәш-кабиләгә фаш буласын! Бөтен гайбәтче хатыннар, кызларның авызында сагыз кебек әүмәләнеп йөрисең. Әнә теге мишәр кызы кызык иде...»

Эче борырга тотынды. Тәненнән әллә нинди салкын бер агым үтте, башка бер кызу ут кебек нәрсә бердән капты.

Күңеле болгана башлады. Ул көчкә генә тазга барып өлгерде. Зәкъкум тәмләре чыгарып косу башланды. Бу көнге чәе, берничә кисәк күмәче

арасында кызыллы-яшеллерәк ит калҗасы күзгә ташланды. Күңелгә бердән «кичә ресторанда дуңгыз ите бирелгән» дигән уй керде. Керде генә түгел, тәмам шулай дип ышану утырды. Шул уйның урынлашуы булмады, аңарда тагы укшу башланды, аның бөтен тәне, бөтен әгъзалары шул хәрам дуңгыз итен куып чыгарыр өчен бар көчене җыеп һөҗүм ясады. Эченең әллә кай җирләрендә әллә нинди зур тулкыннар купты. Калтырана-калтырана ул башын күтәргәндә, күзеннән яшен сөрткәндә үзенең тәмам хәле киткәнне хис итте. Диварларга тотына-тотына гына урынына барып ятты. Бик озак өн белән төн арасында йоклар-йокламас изелеп ятты. Аз гына күз ача башлагач та ул, әллә нәрсәгә бик эче пошканны хис итеп, шуның сәбәбене эзләргә кереште. Бүлмәсенең тузганлыгын күреп, бүлмәдәге чүп-чарга ачуы килеп асраугa звонок бирде. Үзе тагы яртылый киенгән көенчә урынына ауды.

Менә бервакытны ишекне шакыган кебек булды. Ул йокыдан уянып киттеме, исерүеннән айнып киттеме, әллә нинди аптырауда калды. Ишек шакуы ап-ачык ишетелде. Ул шуңарга ни әйтергә, ни эшләргә вә ни уйларга өлгермәде: «К вам можно?» — дигән Мария Ивановнаның тавышыны ишетте. Шул чуалчык башка аның тавышы тагы йомшаграк, тагы хәтфәлерәк кебек тоелды. Ул тиз өстене юрган белән яшереп: «Можно, можно»,— диде. Акрын гына ишек ачылып, Мария Ивановна керде. Бердән аның бөтен кыяфәте Хәмитнең күзенә ташланды. Әллә нинди куркумы, шөбһәләнү, икеләнүме буявы сызылган...

Күзләренә ихтирамны, шәфкатьме нуры сибелгән, көлүенә тагы бер йомшаклык, аналарның балаларыны сөйгән чакларындагы җылы йомшаклык арттырылган.

Ул тиз генә Хәмит әфәнденең янына килеп кулын бирде. Аның белән бергә Хәмитнең борынына пөхтә генә, нәфис кенә бер ис килеп керде. Әллә нәрсә исе. Шул исне ул әллә кая гына, юкә чәчәк атканда тойган иде. Ул аның борыныны кытыклады. Аңарга әллә кай бер җире белән тәэсир итте. Аның күңелендә шатлык кебек бернәрсә уятты. Ул Мария Ивановнаның кулында да бу юлы аерым бер җылылык, аерым бер йомшак җылылык хис итте. Мария

Ивановна авыруны озак сорап тормады, кулы белән башын тотты. Хәмит салкынча гына бер кулны вә шул кулдан агып бара торган, мо-ңарга әллә нинди рәхәт, тынычлык бирә торган бер агымны сизенде, шул агымның әллә кайбер җиренең тибүен хис итте. Мария Ивановна кулын алгач та Хәмитнең күңелендә әллә нәрсәсе югалган кебек булды. Ул: «Алма, торсын, ул кул миңа тынычлык агыза»,—димәкче булды, әйтә алмады. Мария Ивановна күзләре белән Хәмит әфәнденең бүлмәсен җентекләп чыкты. Үзе һаман йөзеннән көлемчелекне бетермәенчә, доктор чакыру-чакырмау хакында сорап алды:

— Тәнеңездә эсселек бар!.. Үлчәдеңезме?

— Юк.

Мария Ивановна Хәмитнең күңелен ачар өчен банкадагы яңа хәбәрләрне сөйләсә дә, аның белән дә күңелендә әйтергә теләгән эшне әйтә алмады булырга кирәк, ул бераз кызарып: «Сезнең бүлмәңезне бераз рәтләргә мөмкинме?» — диде. Хәмит: «Рәхмәт»,— диюенә каршы ул, торып, бүлмәнең тышына чыкты. Анда хуҗа хатын белән әллә ни сөйләп асрауны алып керде. Чәй урынын җыйдырды, тазны түктерде. Өстәл өстендә төрле-төрле кара вә ак якаларын җыйды. Таралган китаплар, газеталарга җыелган төс бирде. Киемнәрне тышка чыгартты. Бер нәрсәне бер урыннан алды, икенчесен куйды.

Әллә нишләде, әллә нишләде. Бүлмәгә ямь кереп китте.

Хәмит Мария Ивановнадан күзен ала алмаенча катты. Ул үзенең авыруын да онытып, үзенең өйләнергә йөри торган дәртле егет икәнен дә башыннан кичерде. Аның һәр хәрәкәте, һәр селкенүе Хәмитнең күңеленә әллә нинди тынычлык, уңайлык коеп торганга, ул коендырып салган бала кебек изрәп рәхәтләнеп китте. Аның янына тагы Мария Ивановна килеп утыргач, ул тагы аның пөхтә нәфис исенең якынлыгын хис иткәч, аның йөзен елмаю, шатлыклы бер елмаю каплады. Ул кулын сузып Мария Ивановнаның кулын кысты: «Рәхмәт, рәхмәт! Сез минем өемә ямь керттеңез»,—диде. Ләкин кысуы артыграк булдымы, әллә мәгънәсе башкарак чыктымы, Мария Ивановнаның йөзен нечкә генә алсу бер оялу япты. Аның бите-йөзе тагы матураеп китте.

Аның күзләренә тагы яңа рух, яңа нур сачелде. Әллә кай җирендә шатланганы, әллә ни өчен кәефлеләнгәне әллә нинди бер юл белән хис ителде.

Ул чыгып киткәч, Хәмит әфәнде әллә нәрсәсен югалткан, әллә нинди газиз нәрсәсен урлаткан кебек булды. Эч пошу басты. Баш авыртуы хис ителә башлады. Күңелгә ямьсез-ямьсез уйлар тулды.

Ник: «Китмә! Тор!» — димәдем?

Ул аның чыгып киткән ишегенә карады. Ул ишек төбендә анын «хуш» дигән актыккы сүзен әйткәндәге елмаюын тагы күреп, тагы зур, газиз, кадерле бер нәрсәсен югалту хисе астында изелде.

## VIII

Шабыр тир эчендә.

Соң әле ни булды? Йокладымы, уяндымы? Кем тирләгән? Хәмитме? Юрганмы? Ник мендәрләр талгын гына, төче генә ис белән җебегән бүлмәнен эченә әбиләр атнасындагы кебек сыек кына сөрен сибелгән. Лампаның януында, анын иренеп кенә януында әллә нинди бер дәм бар. Бүлмә әллә нәрсәгә тилмереп-тилмереп карыймы шунда? Әллә эчендәге авыр бер іскә эче пошып чырайларын сытамы? Соң, тукта әле, ни булды? Ник тән чыланган кебек булып, бер туңган кебек булып китә. Баш авыртамы? Юкмы?.. Чын, нинди җиңел! Юк, һәммәсе бар. Менә кулы. Менә башы, менә гәүдәсе?.. Чын, бар...

Ул шул «барны» кулы белән сизәр өчен башын капшарга кулын сузды. Юрганның ярыгыннан бер агым аның ачык күкрәген салкын авызы белән үпте.

Аның тирле кулын, суык һава килеп кочаклады. Ул «брр» итеп калтырап китте, тиз-тиз кулларын, башларын тагы яшерде. Дымлы гына, салмак кына юрган үзенең бәреп килә торган исе белән аның өстенә тып кына ятты.

Юк, бөтен әгъзам бар. Һәммәсе бар, теге албасты гына юк...

Әнә нинди җиңел уй йөри. Әнә аяклар берсе өстенә берсе ничек куела... Ә нинди юеш, соң ни булды?...

Ни булды?.. Мария Ивановна килде... Бүлмәне җыештырды. Пөхтә генә бер ис калдырды. Тукта әле, исним әле, бармы? Бар. Аннан соң тулы гына. Симез генә, зур корсаклы бер доктор килде... Аннан соң?.. Иптәше Вахит алмалар алып килде... Аннан соң ... Ул әчеле-төчеле бер дару эчте... Әһә, ул бит авырый. Шул уен ныгытыр өчен кебек аның бөтен тәне сызлап китте. Буыннары, тамырлары авырсынып, сыкрап куйды. Башына бердән чуен койган кебек булып катып китте. Авызына тагы теге тәм, черегән чикләвек тәме йөгерде. Күңелгә жу итеп: «Авырыйм, чынлап авырыйм, үләм»,— дигән фикер керде.

Үлсәм?..

Шул уй белән бергә аның бөтен тирә-янын бер тынлык каплады. Әллә нинди бушлыкка чумды. Әллә нинди салкынлы-җылылы юклыкта йөзә. Бата башлады. Менә ул үлде... Хәмит үлде, үлде... Шуннан ни булды?.. Берни булмады, үлде... Хәмит дигән бер кеше бар иде, шул юкка әверелде. Ул сөйли иде, тавышы өзедде.Уйлый иде, фикере туктады. Яшь иде, тора иде, катты, бетте. Бетте?..

Шулай ук беттеме? Берни калмаенча беттеме?..

Ул менә утыз ел торды, утыз ел әллә ниләр эшләде. Утыз ел әллә ниләр уйлады. Утыз ел әллә нидер төшенде, утыз ел әллә нидер тудырмакчы булды... Утыз ел әллә нидер ясамакчы, арттырмакчы булды... Шуларның берсе дә булмаенча беттеме? Мәңгегә, булмаска беттеме?.. Аны салкын бер агым кочаклады, тешләре шыкылдарга, төне өшергә, тунарга кереште.

Юк, бетмәде. Хәмит үлсә дә, Хәмит әфәнде үзе үлсә дә, аның үлмәгән... үлмәячәк... бетмәячәк... Ул көчәнеп кенә «эше» дигән сүзне кушты. Шул уйга ышанмаганга булырга кирәк, ул тавышын зурайта - зурайта: «Хәмит әфәнде үзе үлсә дә, аның үлмәячәк эше калды»,— дигән сүзен берничә кат тәкрарлады. Нинди эш? Әйе, нинди эшме! Бик күп эш... Мәсәлән... мәсәлән, әфәндем... ымм, мәсәлән, ул, Хәмит әфәнде...

Хәмит әфәнде...

Әйе, Хәмит әфәнде...

Мәсәлән, Сату-алу эшендә...

Ул...

Бер фирма тудырдымы?

Юк ла, юк... Ул әллә нинди хисаплар ясады. Әллә нинди исәпләр язды, әллә кемнең векселен протестка кертте. Әллә кемне судка бирдерде...

Юк, ул түгел... Ул җәмәгать эшендә, мәсәлән... мәсәлән, әфәндем... Ул җәмгыяте хәйриягә әгъза булды...

Ул гына димени? Кеше үзе өчен генә тора алмыймыни? Хәмит әфәнде үзе өчен, үз гаиләсе өчен торды, ул сөйде... сөйде?..

Әйе, әйе, сөйде.

Кемне сөйде?.. Тукта әле, сөйде, төгаен белә,сөйде...

Кемне сон? Ә теге мишәр кызын... Әллә Мария Ивановнамы?..

Әллә теге авылларындагы мөгаллимәнеме?

Юк. Түгел, ул былтыр театрда иттифакый очрап киткән Троискидан килгән яшь байның хатынын сөйде... Ул никадәр башын көчләп, үзенең тормышының мәгънәләрен эзләсә дә, ул ят кешене ышандырырлык әллә никадәр дәлилләр китерә алса да, үзен-үзе канәгатьләндерә алмады, үзен-үзе шул коточкыч бушлык упкынынннан яшерә алмады. Күңеленең бер почмагында: «Мин үләм, мин бетәм, мин мәңгегә бетәм»,— дигән фикер-уй үскәннән үсте. Ул аның бөтен башын, йөрәген каплады, аның бөтен уен томалады.

Әйе. Үләм... Мәңгегә бетәм...

Аның күз алдына җеназасы килде. Менә бала исеме кушарга барырга ашыга-ашыга мулла җеназа намазы укый... Әнә аны дустлары, иптәшләре күтәрделәр... Кызу-кызу итеп йөгерткән кебек алып баралар... Һәммәсенең йөзенә бурычны үтәү, күңелсез бурычны үтәү төсе чыккан. Менә килделәр, төшерделәр. Кабер казучылар харчевняга кереп тизрәк ашын ашар өчен кызу-

кызу күмәләр. Мөәззин өйгә кайтып иркенләп чәй эчәр өчен «Тәбарәк»не кызу-кызу укый...

Бөтен дустлар, иптәшләр тизрәк-тизрәк дип, догаларга кул күтәрәләр, менә тордылар.

Хәмит ялгыз караңгы җир астында калды. Алар ашыга-ашыга килә торган вагонга өлгерер өчен чаба-чаба киттеләр. Аларның берсе дә «Хәмит бит ялгыз калды...» дип артына әйләнеп карамады. «Хуш, иптәш, хуш, дуст!» дип, берсе күзеннән бер бөртек яшен чыгармады... Менә кайттылар. Барысы да туңганнар, өшегәннәр.

Вахитның Фатыймасы: «Суык тидермәдеңме? Минем әти Әхмәтҗан абзыйны күмгәндә суык алдырып өч атна яткан иде. Тизрәк чәйгә утыр»,—диде. Шакирҗанның Әсмасы асраугa: «Тизрәк бул, тизрәк, абзаң кайтты»,—дип кычкырды. Үзе җылы су күтәреп: «Юын да утыр... Төсләрең күгәреп киткән... Җил генәдер лә...» —диде.

Шәйхулланың дүрт баласы: «Әти, әти!» — дип, аны тишенергә бирмәенчә чормап алдылар. Алар берсе бер ягыннан сикереп, икенчесе икенче ягыннан сикереп, аның тирәсендә әйләнделәр.

Менә Садрелислам, Шәмсетдин, Фәтхулла беренче ресторанга кереп чәйгә утырдылар. Берәрне эчеп җылынгач, Шәмсетдин яңа бер хәбәр әйткән кебек: «Хәмит үлде бит, ә егетләр?» — диде.

Тегеләр дә: «Үлде, үлде»,—дип җавап бирделәр дә, тагы үзләренең хезмәтләре хакында

Кардәше, кабиләсе?.. Хәмитнең кабиләсе бармыни?..

Теге уңмаган җиңгәсе белән үз хатыныннан да шәп кеше юк дип ышанган абзыйсымы?...

Әйе, ул да менә хат алды: «Энең Хәмит февраль аеның егерме сигезендә вафат булды»,—дигән...

— Хатын... Хатын, безнең Хәмит үлгән бит...

— Тукта әле, эчемне пошырма әле, әле дә камырым ачып ташкан.

— Хәмит әфәнде? Нинди Хәмит?

— Үземезнең Хәмит...

— Муллаҗан агаймы?.. И-и нишләп үлгән?..

— Аның малы, дәүләте калгандыр... Син анда барып килмәенчә булмас...

Чын да Хәмит бит менә үлә, үлә түгел, бетә... Бөтенләй югала. Бу дөньяда онытыла, бетә... Менә бит аның чын да дәүләте-малы бар... Акчасы бар, киеме-салымы бар, китабы-фәләне бар... Әйе, бар. Шуларны соң кемгә калдырырга?.. Тукта әле чын да: кемгә?.. Китапларын иң якын кешесенә? Кем соң ул?.. Улмы? Ул, әфәндем, бик күп... Хәмитнең дустлары бик күп...

Теге мишәр кызына альбомны!.. Әйе. Акчасыны?.. Акчасыны?.. Чын да, акчасыны кемгә?.. Соң чын да бит Хәмитнең әллә никадәр дусты-ише бар, әллә никадәр якыны бар, бар... бар, ләкин... ләкин... шулар арасында, Хәмитнең «үзе», «үз кеше» кем?

Агасының уңмаган үз хатыны бар.

Нәсыйхулланың үз балалары бар.

Фәсахетдиннең үз анасы бар.

Шәмсетдиннең үз энесе бар.

Хәмитнең?..

Утыз ел эчендә шулай бер кеше белән дә үзләнә алмадымыни? Бер кешегә дә «үзлеген» бирә алмадымыни?.. Шуларга җавап булган «юк», зур бер «юк» аны тагы калтыратты, аның бөтен җаны өшеп, күңелене зыяндаш тота башлады... Тирә-юнь тагы бушлык, юклыкка батты...

## IX

Ишек шакылдый, акыртын гына ачылып, Кәлимулла абзый килеп керде. Ул читтән үк көлеп кереп: «Исәнме, Хәмит? Тереләсеңме?» — диде.

Үзе ят бер йиргә кергән кебек тирә-юньне караныргa, шул ят бүлмәне исе киткән кебек җентекләргә керéште. Аның белән Хәмит сөйләшергә, сорашырга өлгермәде, Шәйхулла килеп җитте. Алар өстенә Фәхри абзый килеп, өчесе дә Хәмитнең авыруы бетәчәген сөйләделәр. Өчесе дә шәһәрдәге

яңа хәбәрләрне, яңа гайбәтләрне актардылар. Өчесе дә бергәләп сүз төенләп килгән кебек итеп, Хәмитне өйләнергә димләргә керештеләр. Бик озын иттереп сөйләгәннең соңында, Мария Ивановна кергәч кенә торып киттеләр. Ләкин киткәндә: «Терелеп бет дә, өйләндерәмез, җитте, Хәмит!» — дип чыгып киттеләр. Шул «өйләндерәмез» дигән сүз Мария Ивановнаның, теге, бәхеткә, нечкә исенә буялып, Хәмитнең күзе алдында матур манзаралар уятты. Ул аның тагы хыялыны йөздереп китеп, балалар белән үзен чолгаткан итеп күрде. Тагы үзенең авыру икәнен исәпләп уен туктатырга теләсә дә: «Әйе, мин авыру, менә минем хатыным баш очыма утырган. Кем әле ул, Әсмамы? Фатыймамы?.. Фәхрелнисамы?.. Әллә Мария, Катеринамы?.. Әнә балалары, этиләре үләчәкне белмәенчә, уйнап йөриләр. Менә ул үлде, менә ул бетте...

Юк, ул бетмәде... Әнә аның үзе төсле үк «үз угылы» калды. Әнә аның үзе кебек кызы, «үз кызы» калды. Әнә аның бөтен китаплары, киемнәре, бөтен малына ия табылды... табылды... һәммәсенә табылды...

Ул зур албасты пәрине өстеннән ташлаган кебек җиңеләеп китте.

Өйләнергә, терелдем исә өйләнергә?.. Уйламыйча-нитмичә өйләнергә...»

Тәрәзәдән төшкән кояш шәфкатьлерәк кебек сизелде. Бүлмәне тутырган якты өметлерәк кебек тоелды.

Терелеп җитеп, эшкә чыккач та, аның беренче уе шул өйләнүне тәмамлау булды. Ул никадәр сузсаң, шулкадәр сузылачагына ышанып, никадәр нечкәләсәң, шулкадәр өзеләчәк нокталары күбәячәген күреп: «Әйе, өйләнәм!» — дип карар ясады да куйды. Вә шул карарны мөмкин кадәр эшкә чыгарыр өчен, ул әлеге дуст-ишкә кыз димләргә үтенде. Шул ук кичне Әхмәдиләрдәге дуст-иш мәҗлесендә мәсьәлә бөтен аш өсте белән тикшерелде. Хәмитнең өйләнүе бөтен вакларына кадәр җентекләнде. Тирә-юньдәге җиткән кызлар тагы сайлау базарына куелды. Әсма абыстай үзенең тудыгының кызы Гарифәне мәслихәт күрде, ул аның, матурлык, зифа буена башка, тәрбиялелеген, этисе, әнисенең указлы мөәззиннәр икәнен дә кушты. Хәлимә абыстай, Хәмит әфәндегә мөәззин кызлары азрак булачагын алга сөреп, шул

шәһәрдәге әтисе-әнисе үлеп, әбисендә генә тора торган; бай кызы Сәлимәне димләде: «Ул үзе русча укыган. Үзе, русча киенә. Үзен рус обществасында тота белә. Биегәндә, танцевать иткәндә аның татар кызы икәнен белмәенчә аптырап калалар. Бер эфисәр менә әле күптән түгел генә: «Сезне мин һич татаркага охшатмаган идем»,— дип, мактаган...»

Фәхри абыстай: «Хәмит ул бит андый марҗа сыманнарны яратмас. Аңарга яңа татар кызы, татар әдәбияты укыган, татар матбугаты артыннан бара торган кыз кирәк. Шулай бит, Хәмит!»—диде. Хәмит җаваплы иттергән кебек башын иде. Шуны гына көткән кебек, Мәрфуга абыстай: «Менә безнең авылда бик һәйбәт бер хатын бар. Сезгә бит, Хәмит әфәнде, тол булса да зарар юктыр. Мулла хатыны иде. Мулласы белән дүрт кенә ел тордылар. Үлде, мескен, балаларны бик яхшы укыта иде. Әле хәзер шул абыстай кызлар укытып тора, ике генә баласы бар»,—диде. Аның шул сүзләре бик күп хатыннарга ошамаган кебек, ирләрдән дә тавыш-туыш күтәрде. «Ярамый, ярамый. Җиләк кебек егеткә тол хатыннан башкасы беткәндер?..»

«Әйе, әйе, шулай, шулай. Ул тагы бит тол хатыннар гомергә иске ирләрен онытмыйлар, ди. Синең берлән бер өйдә торса, бер табактан аш ашаса, бер түшәктә ятса, үзе күңеленнән теге ире берлән яшәсә, ул нинди тормыш. Хәмит егет кеше, кыз аламыз, кыз»,— диделәр.

Вә тагы кызларның исемнәре, сыйфатлары үстерелә башлады.

Шәйхетдин әфәнде: «Юк инде, ул, Хәмит әфәнде, гаилә ясарга булгач, хатынның укыганын алырга кирәк. Син эш кешесе, ул сиңа өендә тынычлык бирсен. Сиңа эшендә ярдәмче булсын. Сиңа укыган кирәк».

Мөәззин кызын димләүче абыстай да, бай кызына яучы булырга теләүче кодача да, һәммәсе дә шуңарга разый булды, һәммәсе укыганнардан эзләргә тотындылар.

— Хәзер укыганнар да күп. Менә, үземезнең шәһәрдә үк, Габдерахманның кызы гимназиядә укып йөри. Чибәр генә, зифа гына кыз. Хәмит, күргәнең бармы? Әнә әдәбият кичәсендә күгелҗем күлмәктән иде.

Аннан әнә, теге Касыймнан килгән кыз бар. Ул, тагы, бай кызы, ди. Атасының әллә ничә җирдә буфеты бар, ресторан-вагоннар бар, ди.

— Юк инде, ул, егетләр, укыганга өйләнгәч-өйләнгәч, эшкә керешкәне кирәк. Менә Оренбургта бер доктор бар, ди. Аена дүрт-биш йөз сумнан ким эшләми, ди. Менә кем кирәк, Хәмит?.. Дөньяның төрле хәле бар. Һөнәр зарар итми...

Хәмитнең: «Ул бит миңа чыкмас»,— дигән сүзенә ире-хатыны беравыздан: «Кемгә чыксын?.. Сиңа да чыкмагач, кемгә чыксын?.. Чыга, чыга»,—диештеләр. Читтә генә тыңлап тора торган маклер Госманов: «Хәмит әфәнде, монда бер польский генерал бар. Шуның ике генә баласы бар. Икесе дә кыз. Берсе хәзер бер полковникта, берсе әле институтта укый, төскә-буйга йиткән.Мин аларга монда йорт караган идем. Үзе бик мөселман, генерал башы берлән уразасын калдырмый. Шуңарга сөйләп караганда, серне ачканда ничек булыр иде. Утарлары бар. Болай байлык зур, тору боярча».

Ул сүзне бетерә алмады, карт кына приказчик; «Хәмит, чыдаган, чыда инде. Бер ел үтәр, ике ел үтәр. Безнең Салих абзый үлә бит. Яшь хатын нинди кала! Бер кашык су белән йотарсың бит. Ул дәүләт дисеңме? Ул йорт-җир дисенме? Һәммәсе хәзер, һәммәсе урынында. Керәсең дә утырасың. Минем хатын аларга керделе-чыктылы. Теләсәң, хәзердән сүз алып куеп була. Карт хәзер түшәктә...»

Шуларга башка, берсе Сибириядан иреннән качып кайткан бер хатынны, берсе рус боярларында унике ел торып бөтен аш-суның серләрен белеп чыккан, акча да җыя алган бер кызны, берсе Петербургта адвокатлыкта укып ята торган бер курсистканы, берсе шәһәрнең мөгаллимәсен, берсе харчевня тота торган бер мишәрнең тол кызын, берсе беркем дә белмәгән, күрмәгән бер әбинең унбиш-уналты яшьлек кызын димләде...

Һәммәсе үзенең сүзен тормыштан алган әллә никадәр мисаллар берлән беркетте. Һәммәсе үзенең димләгән кешесендә генә бәхет ачкычы иттереп күрсәтте. Ләкин, шуларның һәммәсеннән дә Хәмитнең башындагы «өйләнү» дигән уй, фикер чуала гына барды, һәрбер яңы сүздән соң, аның фикере, аның

теләгәненчә иттереп бетерелүе авырая гына барды. Төннең яртысында таралганда, ишек төбендә тагы, яңы кызлар, яңы бикәчләр табылса да, тагы, шул томан, шул белемсезлек арта гына барды... Аяк астында шыгырдый торган карларны үтә-үтә тар урамнан зур урамга чыккач кына, Хәмитнең иске иптәше Сәгыйть куып җитте. Вә тагы шул мәсьәләгә кайтып: «Мин, Хәмит, сиңа бер кыз да димләмәдем. Син үпкәләмә, андый эшне болай эшләп булмый. Иң яхшысы үзең бер кызны төбәп алу да, шуны булдырырга тырышу. Кешенең ни теләгәнен дуст-иш, иң якыннары да белми. Белә алмады да... Шуның өчен син, вакыт үтә димәсәң, Петербург, Мәскәүнең вечерларын көт, шунда барып өстән-өстән генә карап үт, күңелгә тулган кебек үк булды исә, тот та таныш. Иң беренчесе шул — бөтен шартлары килеп җитмәүгә разый булу».

Хәмит тагы аптырап калды. Ул үзенең шул мәсьәләне никадәр сузсаң, шулкадәр сузылачагына ышанганлыгын сөйләп, шул тизрәк бер арада, катгыйрак бер хәрәкәт ясарга карар иткәнен сөйләде.

Сәгыйть: «Алай булса, менә нәрсә, минем хатын әллә кайчаннан бирле йөдәтә торган бер мәсьәлә бар. Шәһәрдә бай гына, уңган гына бер кеше бар. Шуның буйга җиткән бер кызы бар. Үзем күргәнем, белгәнем кешеләр түгел. Минем хатын бик белә. Мактый-мактый йөдәп чыга... Кыз русча да үзен тотарлык укыган. Мөселманча яхшы. Кием-салымны йөртә белә. Йорт тотарга өйрәнгән, уңган, матур, ди. Атасы шактый бай кеше. Үзләренчә зыялылардан. Кызларын качырмыйлар. Хатыннар бит шундый да сөйләргә яраталар! Минем хатын сезнең хакта сөйләгән дә булырга кирәк. Теләсәң, шунда барып кил. Шәһәре шактый гына, бу арада бит өч көн бәйрәм, күңел ачылып килер. Күрешерсез, белешерсез. Театрына, кинематографына барырсыз. Теләсәң, мин иртүк хатыннан «бер кунак бара» дип, хат яздыра алам».

Хәмит: «Безнең кече атна бит бәйрәм. Мин өч-дүрт көн йөреп кайтыйм. Ләкин беркемгә дә сөйләмә».

Урам чатына йитеп аерылышканда Хәмит: «Шулай, алай булса, вәгъдә, мин хәзерләнәм»,—диде. Сәгыйть: «Шулай, шулай,— дигәч, Хәмит

җиңеләйгән кебек, йөген ташлаган кебек, тиз-тиз өенә борылды. Шул карарда күңелен ныгыткангамы төшсез-нисез, бик тыныч йокыда үткәрде.

Вокзалда Хәмитне Сәгыйтьтән башка беркем дә озатмады.

Аның китүе дә вокзал тулы сөт китергән марҗаларның, шәһәргә мал алырга килгән сәүдәгәрләрнең китүеннән бертөрле дә аерынкыланмады. Өченче звонокны суккач кына, кулны кулга алып күрешкәч кенә Сәгыйть: «Хәерле юлга, онытма — «Европа» нумирлары. Андый-мондый эш чыкса, телеграм гына бир. Мин һәрвакыт синең ихтыярда»,— диде. Хәмит рәхмәт укып, баш иярге өлгермәде, поезд ялкау гына, салмак кына атлый башлады. Әллә нинди, Дәҗҗал сулаган тавышларны чыгарып, Сәгыйтьнең әллә нинди сүзләрен колактан ерагайта башлады. Хәмит тагы бер мәртәбә башын иде. Сәгыйть елмайды. Иреннәрен кыймылдатты. Башын бер ике-өч мәртәбә иде. Поездның йөрүе берлә дә очып, биткә бәрелә торган карлар күбәя башлагач, Хәмит акыртын гына вагонга керде.

Караңгы гына, моң гына вагон... Бер почмакта ирле-хатынлы җуан гына кешеләр утырганнар да, алларына кәгазьләр җәеп, ашарга хәзерләнәләр. Хатыны кыска гына, тулы гына куллары берлән зур бер төеннән төрле кәгазьгә төргән тутырмалар, майлар, пәйнирлар чыгара бирә, ире ак саплы пәке берлән зур бер калачны күкрәккә терәп кисә бирә. Вагонның кечкенә өстәле тулганына карамаеңча, ул һаман калачның иңеннән буена пычак берлән еруында дәвам итә. Яшь кенә бер хатын тәрәзәгә маңлаен терәгән дә, шул караңгы сахралардан әллә нәрсә эзләгән кебек, каткан да калган... Ул селкенми, хәрәкәтләнми... Карый, әллә ни карый... Өч-дүрт балалы бер марҗа бер баласын бер якта, берсен икенче якка салырга урыннар хәзерли. Шәлгә бәйләгән төеннән кечкенә мендәрләр, корамадан җыеп ясаган юрганнар чыгара... Урыннар рәтли, балаларын яткыра, сыйпый, сөя, кага...

Чиновник кыяфәтендәге бер кеше бер аягын берсе өстенә куйган да, зур бер гәзитәне ачкан да укый, бөтен дикъкатен шуңарга борган да, шул зур кәгазьдән тормышның бөтен хикмәтен сөреп алырга теләгән кебек, текәлгән, кадалган...

Жуан гына бер кеше, кайвакыт кереп өлгергән, кайвакыт урын хәзерләп өлгергән, бөтен вагонны дерелдәтеп, гырлап-гырлап йоклый.

Яшь кенә бер егет зифа гына бер кызга таба борылган да бик акрын гына тавыш берлән әллә нидер сөйли. Кыз да башын аз гына яшь егет тарафына бөккән дә чумып тыңлый, күзе берлән, йөзе берлән тегенең сүзләренә чумып тыңлый.

Шәкерт сыман бер егет бертуктамаенча, әле бер ишектән кереп, әле берсеннән чыгып, әллә ни эзләгән кебек чуалып йөри. Күп кеше ятарга урыннар сала... Төеннәр тишә.

Хәмит тә акыртын гына аркасын диварга терәп, аякларын аякка куйды. Аркадан килә торган вагонның дерелдәве аның да уйларын тирбәтә, хыялландыра башлады. Менә Хәмит китте... Өйләнергә дип китте. Белмәгән бер шәһәргә бара да, белмәгән-күрмәгән бер гаиләгә үзен өйләнергә йөрүче дип таныта да, колак ишетмәгән, күз күрмәгән бер кызга ярарга, яратылырга тырыша, сөяргә-сөелергә тырыша... Моннан да мантыйксызлык, моннан да ахмаклык булырмы?.. Әйе, шулай шул... Ләкин гакыллы булып утырып торсаң, әллә кайдан табигый көенчә генә үзеңә ошаганны, үзең аңарга ошаганны, чыгар әле, дип авыз ачып торсаң, шул гакылдан ни чыгачак? Көн саен көн үтәчәк, көн саен гомер кимиячәк. Көн саен үзеңнең хатын булачак кешегә куелачак шартлар күбәячәк. Көн саен картаелачак, гаилә хәятында бөгелергә, сыгылырга тиеш булган буыннар, тамырлар катачак... Юк, исмасам, гомердә бер мәртәбә шул ахмаклыкны кылырга да, тыныш куярга... Әйе, шулай. Элгәре кызык булган... Егет үсеп җиттеме, атасы-анасы, кардә-ше-кабиләсе кыз эзләгәннәр... Тапканнар.Туен ясаганнар. Кода-кодагый булганнар. Кияү бүләкләре, туй яраклары хәзерләгәннәр... Егет киенгән-ясанган да, менә әфәндем кияү китте, дип утырган да киткән... Үзе кыска, үзе җиңел. Үзе күңелле... Минем дә шундый атам-анам булса, хәзер тыр-тыр итеп тилереп йөрмәс идем...

Юк шул, әфәндем, без хәзер элгәреге авыл егете, элгәреге: «Дөнья нине бирде — хуп»,— дип, каршы ала торган тәкъдир бәндәсе түгел... Тормышны

үземез ясамакчы, үземез кормакчы буламыз. Без яңы кешеләр... Без үземез эзлимез, без үземез табамыз... Без үземез һәрнәрсәгә үзлек бирәмез... Без... без...

Менә мин хәзер үзем эзләргә, үзем табарга, үзем бер ят тәрбиядә үскән, белемсез, тирә-юньдә зурайган бер кызны «үзем» итәргә барам. Бәйрәм арасында бушаган вакытта үзем ата булам да, шуның берлән, бик белгән бер әгъза иттереп, гаилә корам. Шуны бик сөйгән иттереп, үземә гомерлеккә иптәш ясыйм. Түгел шул, без яңы да түгел, иске дә түгел... Кем соң? Әллә кем генә... Безме? Без иске тормыш ватылгандагы чүп-чар... Иске тормыш яңыга аугандагы коелган, таралган китекләр... Без иске тормышның тынышы, яңы тормыш башланып киткәндә тын ала торган тынышы... Менә бездән, ягъни безнең янымыздан яңы тормыш башланып китәчәк... Безнең тарихи урынымыз тыныш булыр... Ике тормышның берсеннән берсен аерылганын ачыграк күрсәтү... Менә, шул вазыйфаны белеп, шул тыныш үзенең юлы арасында чабып йөрмәсен өчен, бер тыныш, икенче бер тынышны үз яныма куймакчы булам. Әйе, куймакчы булам... Шуның өчен, әллә кемне алмакчы булып, менә тыр-тыр барам... Аны механически гына алып куймакчы булам. Әйе, тыныш бит ул. Ул сүз дә түгел. Сүз башы да түгел. Ул тыныш, аның матурлыгы-ямьсезлегенең кыйммәте юк. Ул ачык булып, зураеп, ике юлны берсеннән берсен, ике җөмләне берсеннән берсен аерып торсын... Ул кыз — мин ярата торган кыз. Марҗаны йөдәтә-йөдәтә кием өлгерттерә торган, иртәдән алып кичкә кадәр киенеп-ясанып кием төрли торгандыр. Шул мантыйксызлыклар, шул борчылулар һәммәсе тынышлык өчен генә икәнен беләме?.. Юк, ул белми... Ул бәхетле, ул әле белерлек дәрәҗәдә укымаган... Ул әле: «Мин сүз башы булам, яңы тормышта хуҗа булам»,— дип уйлый... Бәхетле...

Поезд бер туктады, бер кузгалды. Хәмитнең фикере бер өзелде, бер ялганды... Баш арыды, эче пошты. Күзләренә йокы тулды. Ул мендәрләрен чишмәенчә, сөялә-сөялә генә йокыга китте. Юына-нитә тормаенча, кечкенә генә сумкасын, мендәрләрен күтәреп, шәһәргә чыкканда, кояш чыккан, көн яктырган иде. Иртәнге саф суык яшь көче белән яңа көнне каршы ала иде.

Хәмит йоклар-йокламас тора торган извозчикларга: «Европейские номера»,— дип кычкырды. Әйберләрен куйганда, тирә-юньдә генә әллә кемне каршы алучымы, озатучымы, берничә мөселман егетләре, бер читтәрәк кенә, таза гына киенгән бер мөселман хатыны күзенә чагылды. Суык колакларны чеметкәли башлагач, яканы күтәреп утырды. Ат кузгалды.

***

Нумирда юынып, киенеп җиткәч тә, самавыр сорап, акыртын гына безли торган керле самавырның тама торган борынынннан китек кырыйлы стаканга бер-ике чынаяк ясап эчкәч тә, акыртын гына урамга чыгып китте. Нияте, әлеге Садыйк Вахитовларга зиярәт белән бару булганга, самавыр китергән малайдан, кайсы урамдалыкны, ничек баруларын сорады. Нумирдан ерак түгел арбачылар булса да, шәһәрне дә күреп үтәрмен, дип, акыртын гына мәсҗед манарасы күренә торган урамга таба борылды. Жансыз кеби урамнарны калдырды. Тар, кыска урамчыкларга керде. Алардан тагы, тәртипсез киң урамнарга борылды. Мөселман исемнәре, фамилияләре язылган вывескалы кибетләр, магазиннарны калдырды. Аларның ишекләреннән чабып чыгып карап калган приказчикларның беләсе килүләрене кытыклап, тагы борылды. Тагы үтте. Менә, урамның чатында гына зур гына ике катлы йорт күзенә ташланды. Сәгыйтьнең тәгърифе, нумирдагы малайның сөйләвенә карап, шул икәнен аңлады. Вә шул аңлау белән бергә күңеленә тагы зур бер шөбһә куелды. Тагы: «Шул йортка барыйммы, бармыйммы?»,— дигән икеләнү басты. Үзен-үзе җиңеп, күңеленнән күркәм, сөекле кыз очратырга дога кылып, акрын гына китте.

Капка төбендә таза атларга төяп, берсе артлы берсе ике йөк тирес чыгаручыга очрады. Аларның үтеп китүләрен көтеп торганда, капканың теге ягындагы таштан салган зур кибеткә күзе төште. Аның тимер ишегене ачып, карт кына бер мөселман хатыны зур гына төендә нәрсәләрдер күтәреп чыкты. Капкадан керүгә йортның артына күзе ташланды, тәбәнәк кенә киртәләрнең теге ягында зур, киң бушлыкта егермеләп зур-зур сыерлар һаваланып, печән

ашыйлар. Аларның яннарында кырыкмыш тайлар уйнашып йөриләр, бик күп сарыклар, сыерлар борыны астыннан урлап-урлап, печәннең каймагын хәрамлап йөриләр. Аның артында озын-озын амбарлар, биек иттереп салынган, тимер берлән ябылган сарайлар. Йортның бер почмагында утын өелгән, озын иттереп, биек иттереп, парахут пристаньнәрендәге кеби утын өелгән. Аларның өстләренә эшләнеп бетмәгән чаналар, дистәләп-дистәләп өелгән арба көпчәкләре, ободлартау иттереп ыргытылган.

Йортның бер почмагында ак кар өстенә ташланган ат тиреләре кылларын туздырып яталар. Койма баганаларының башларында зур мөгезле үгез башлары үзләренең төпсез күзләре белән йортны саклап торалар. Сул якта ике катлы зур озын өй. Капкадан ерак түгел ак ишек, ул пөхтә иттереп эшләнгән... Аңарга электрик звоногы да куелган, мондый тарта торган кыңгырау да тагылган. Хәмит кулын электрик звоногына басты да, күзен югары күтәрде. Югары каттагы тәрәз пәрдәсе селкенде... Әллә нинди тонык кына шәүлә күз алдыннан үтте. Хәмитнең күңеленә тагы шөбһә төште. Тагы: «Ник килдем, ни тилмереп йөрим?» — дигән уй төште. Ул шул уйны уйлап бетерә алмады, бер егет ишекне ачып: «Әйдәңез»,— диде. Хәмит аптырап китте. «Ничек әйдәңез, болар бит әле моны танымыйлар. Ул бит әле менә визит берлән генә килде. Менә кулында визитный карточкасы».

Хәмитнең аптырап торганын күреп, егет: «Әйдәңез! Әйдә»,— ахырдан гына: «Әти өйдә»,— диде.

Хәмит: «Болар мине кемгә багышладылар икән? Бер коммивожер дип белмиләрме икән?» — дип, шөбһәләнә-шөбһәләнә баскычтан менде. Вә ишекне ачып кергәч тә сәлам бирде. Каршы килгән урта яшьле таза гына, озын гына керфекле, симез генә битле бер кешегә кулын сузып:

— Хәмит Әхмәдов,— диде. Теге кеше майлы кулын Хәмиткә сузып күрешсә дә: «Хушыңыз, хушыңыз!»,— дип кычкырып сөйли-сөйли, Хәмит үзен-үзе таныштыруын да ишетмәдеме, илтифатка алмадымы, Хәмитнең пальтәсен салуына күзен төшереп:

— Угылым, кунакның киемен ал,— диде.

Хәмит акыртын гына атлап зур гына, озын гына залга керде. Озын өстәл өстенә чәй урыны хәзерләнгән. Самавыр кайнап тора. Дивар буйларына урындыклар тезелгән. Берничә тәрәзә арасына биек көзгеләр асылган. Тәрәзәләргә челтәрле пәрдәләр тагылган. Бер почмакта зур граммофон йотарга теләгән кеби булып авызын ачып утыра. Өйгә әллә нинди, куй мае берлән бергә катышкан баш помадасы, персидский сирень исләре чыккан...

— Янез, кунак, утырыңыз... Рәхим итеңез. — Хәмит карады. «Утырырга, кая утырырга?» — дигән сөаль берлән бөтен өйне сөзде. Читтә генә бер йомшак диван бар. «Әллә шуңаргамы? Югыйсә, озын өстәл бөтен өйне тутырган да кай ягына утырсаң да, аш янына утырган булачаксың».

Садыйк абзый:

— Рәхим итеңез, түрдән кунак.

Хәмит тагы аптырап калды: «Болар мине бер урын сорый торган мөгаллим, хаҗга баручы бер бәдәлче дип уйламыйлармы икән»,—диергә өлгермәде, Садыйк абзый түр башында бер урынны тартып:

— Рәхим итеңез,— диде. Көтеп тормаенча, үзе дә утырды да:

— Яңез, бер дога,— дип, кул күтәрде.

— Исәнлекме, саулыкмы?

— Әлхәмделиллаһ,— Хәмитнең күзе икенче якка таба ачык торган ишеккә, шул ишек янындагы шкафка төште. Шкафның өстендә әллә никадәр низамсыз газеталар тузылып ята. Почмакларында төрле кәгазьләрдән ясаган чәчәкләр. Эчендә төрле-төрле чынаяклар арасында сөяк саплы револьвер...

Шкаф янындагы тар гына бер этажерка өстендә бик күп өеп куйган граммофон тәрилкәләре. Шулар астында таратылып кына куйган сыек кына төрле-төрле кәгазьдә, төрле-төрле үлчәүдәге яңа татар китаплары — татар әдәбияты. Шуның өстендә диварда зур иттереп Исмәгыйль бәк Гаспринский күзен текәп карап тора. Аның янында оялчан гына, бала гына рәвеше берлән Тукайның күзләре моңаеп тора... Алар янында зур мыеклы Ниязи бәк, аның өстендә ялангач көенчә төшкән бер көрәшче, һәммәсеннән дә читтә, бер

кызның муеныннан үбәргә хәзерләнеп тора торган егетле бер рәсем. Ишек аз гына ачык...

— Угылым, чәй яса әле. Яңез, кунак, рәхим итеңез. Мин әле базардан кайттым. Бүген бездә базар көн... Безнең Сәгыйть исәнме?

— Аллага шөкер, сәламәт. Сәлам әйтте.

Хәмит үзенең танылуын белде. Вә шул зур өстәлнең үзе өчен хәзерләнгәнен дә сизенде. Менә егет өстәл өстен ачты. Пөхтә генә чынаяклар тулы поднос, өстәл янына бер-ике тартмада кәнфитләр, мармаладлар. Бер тәрилкәдә сохарилар, бер тәрилкәдә базар печениесе. Ике якта, ике тәрилкәдә катырган как-төш. Икешәр тәрилкәдә кош телләре. Озын бер тәрилкәдә юкалар, җаймәләр уртасында зур бер калай савытта ап-ак бал, берничә савытта вареньелар... Ишекне ачкан егет Хәмиткә чәй ясап бирде. Садыйк үзе аның алдына мармаладны төртте. Хәмитнең алдында чәкчәк торса да, аны читкәрәк алып, бер ягына сохари, бер ягына печение куйды. Балны үз алдынарак тартып, аллы-гөлле буяудагы помаданы Хәмиткә таба җибәрде. Үзе угылы ясаган чәйне бик тиз генә чөмереп алды.

— Шәһәрдә ни хәбәрләр бар?

— Артык яңа эш юк...

Эченнән генә: «Сон, боларның кызлары чыкмасмы икәнни?»

— Италия дигән бәдбәхет әле һаман төрекләр берлән сугышамы?

— Сугыша әле.

— Кара, бәдбәхетне, кайдан чыкты? Болай безнең эчтә нинди хәбәрләр бар?

— Кичә әле гәзитә укыган идем. Думада заседание булган икән. Родзянко рәислек иткән...

— Угылым, китер әле гәзитәне. Әнә теге мөселман сөннәтчене язган гәзитәне. Менә бит, Аллага шөкер, без дә тәрәккый итә башладык. Сезнең шәһәрдә дә җәмгыяте хәйрия яхшы бара торгандыр. Без дә әле менә монда шундый бер җәмгыять ясамакчы буламыз. Әле, исправник берлән сөйләгән идем. «Давно надо было, Садыкъ Вахитовичъ»,— ди,— аннан соң, менә, ут-

күз бик күп булучан бит, вольный пожарный дружина ясарга кирәк»,— ди. Сөйләшеп карадым да бит, безнең халык бит бик кара, аңлатып булмый. Мулламыз да искерәк кеше, бар белгәне шул ахирәт, ахирәт... Эчеңез, кунак... Угылым, граммофонны борып җибәрмисеңме?»

Егет акыртын гына торып, озын гына борып җибәрде. Граммофон элгәре гөнаһсыз гына чыжлады, пыжлады гына. Аннан соң, әчеле-төчеле тавыш, дүрт-биш хатын бергәләп: «Кашың кара димиләр, сөрмә тарткан димиләр», дип, яшелле-мөшелле тавыш берлән берсеннән-берсе узыша башладылар. Ул бетеп өлгермәде, егет тагы берне алыштырды. Анысында берсе гармун белән әйттерергә кереште. Өченчесендә карылган тавышлы бер кеше иң әүвәл: «Зиләйлүк, милли көй»,—дип кычкырды, шыгыр-шыгыр итә торган гармун көенә кушып, акырырга тотынды.

Хәмитнең йөзенә бертөрле бик үк яратмау чыкканын Садыйк абзый сиздеме:

— Йә әле, угылым, урысчадан куй әле,—диде. Егет борып җибәргәч, граммофон тырт-пырт иттереп бер бию көе уйнарга тотынды, чәй эчелде, граммофон уйнатылды, кыз чыкмады. Хәмит: «Рәхмәт инде, мин туйдым»,— дигәндә генә ишектән зур гына бер урыс килеп керде. Ул Садыйк берлән күрешкәннең соңында, Хәмит берлән дә күреште. Үзе сорап тормаенча да утырды да чәй эчәргә тотынды. Боларга илтифат итмәенчә, русчалап: «Мин, Садыйк Вахидич, синең арттан килдем. Базарда бер айгыр бар. Сиңа төпкә ярамасмы? Карап килик әле. Жуковлар алдылар бит».

Хәмит тагы ясарга теләүгә каршы «рәхмәт» дигәч, Садыйк:

— Бу безнең эш итә торган кешемез. Әле шуның аркасында җир алырга йөримез. Этсез куян тотып булмый бит. Угылым, кунакка карточкаларны күрсәт,— диде. Егет китергән альбомны Хәмит ачты. Беренче биттә Садыйк абзый үзе тора. Ул бумазый күлмәк өстенә җиңсез камзул кигән дә, җуан гына чылбыр берлән сәгать таккан да, чалбарын бурка эченә тыгып кигән дә, ялан баш көенчә басып тора. Аның күршесендә Садыйк абзыйлар гаиләсе булырга кирәк. Садыйк абзый кәләпүшсез казакидан утырган. Аның җилкәсенә,

бөрмәле генә күлмәк кигән, Пенза шәле ябынган моң гына бер абыстай баскан. Садыйк абзыйның бер ягында калфактан гына унике-унөчлек бер кыз, «Менә бу Нәфисә булырга тиеш». Бер ягында менә шул егет, читекле, фәсле малай. Аннары медальләр тагып төшкән бер үрәтник. Аның күршесендә бер җилкәсенә мылтык аскан, бер ягына ике куян эләктергән, кышкы киемгә киенгән баһадир кыяфәтле, үзеннән-үзе разыйлыгына чыдый алмый көлеп тора торган бер аучы рус. Аннары җөббәдән, фәстән бер мөгаллим... Аннары өч-дүрт балалар берлән төшкән бер мөселман гаиләсе. Аннары озын гына, сары гына бер марҗа. Аның күршесендә туй киемендә киенгән, чәчәкләр берлән бизәлгән бер яшь хатын, бер яшь егет. Аннары моң гына басып тора торган, кулына веер тотып калфактан чыккан бер кыз. Бу әлеге Нәфисә, күзе, буе, төсе, бите — һәммәсе дә кешенеке кеби. Аннары тагы, әллә кемнәр, әллә кемнәр...

Урыс болар берлән күрешмәенчә генә чыгып китте. Садыйк абзый болар янына килеп:

— Менә бу якның бояры, без аның урманын алып кистергән идек, әле менә, җире кулга төшмәсме, дип йөримез. Ходай өчен түгел, богдай өчен. Кая әле, угылым, китер әле теге әйберләрне. Менә әле моның тоташы бар иде. Шуңардан сатып алдым. Көмеш сервиз»,— Угылы өстәл өстенә иске боярлар печемендәге әллә никадәр көмеш сервиз китереп куйды. Хәмит берәм-берәм караганда Садыйк абзый:

— Менә шулай инде, бала чагаңа булсын дип маташамыз инде. Гөнаһка да керәсең инде. Мин боларны алганча никадәр хәйләләр корганны белсәң? Бирми дә, бирми бит шәйтан. Ахырдан үзен дә терәдем. Утары залугта, чәчәргә орлыгы юк. Еглады да бирде. Монда, Аллага шөкер, кәсеп бар. Минем язу-сызу гына шәп түгел. Ысулы кадимдә укыган бит. Ике телне дә белгәндә монда эш итеп була. Менә әле күрше авыл башкортларыннан җир алырга йөримез. Бу шунда ярдәм итешә. «Моннан тимер юл үтәр» — диләр. Башкорт каһәрне ашатып туйдырыр хәл юк.

Хәмит: «Рәхмәт!» — дип тора башлагач, Садыйк абзый: «Утыру кирәк иде»,— диде. «Рәхмәт инде»,— дигәч: «Алай булса, ашка рәхим итеңез. Угылым, кунакны айгыр берлән итеп куй. Теләсә, шәһәр күрсәт»,—диде.

Хәмит чыкканда ишек төбендә алмачуар ат бик пөхтә иттереп шәһәр чанасына җигелгән иде. Аның өстендәге камытлары, йөгәннәре, бөтен җиһазлары үзенә азрак зурраграк булып, бер-бер боярдан мирас тарикы берлән килүен күрсәтеп торса да, көмеш тәңкәләре карны оялтырлык итеп ялтырыйлар иде. Ишеккә кадәр озата чыккан Садыйк абзыйга бердән берничә мөселман сәлам бирде. Бер ике-өч урыс баштан бүреген алды. Хәмит тагы бер күрешеп, егет берлән атка утырды. Ат кузгалып, каршы саф һава бәрелә башлагач та, күзен өйгә төшерде. Тәрәзәнең пәрдәсен яртылый ачып карап тора торган калфаклы кызга күзе төште. Шактый озак мәсафә тәрәзә аркылы гына күзләр очрашса да, Хәмит ул күзләрдә берни дә укый алмаган кеби, Нәфисә дә оялчанланып качып китмәде. Шул очрашу Хәмитнең шул хәерче капчыгы манзарәләре берлән тулган башына тагы бер чуалчык кушты. Аңарга Нәфисә зифа төсле күренгән кеби булды. Матур төсле тоелган кеби булды. Үзсүзле, кара эчледер кеби тоелды. Ат пөхтә атлап, кызулап, урам буйлап китте. Кечкенә шәһәрнең берсе артыннан берсе чыгып тора торган өйләре, йортлары, урамнары бик тиз бетте. Хәмит борылып нумирга кайтты. Аш вакыты җитә башлагач, Хәмит уйга калды. Шул визиткасында барса да ярармы, әллә сюртук кисенме, әллә гади киемендә генә барсынмы?...

«Аурупа» нумирларының идәне буе кызулап-кызулап йөрсә дә, кайвакытларда адымнарын акрынайтып, уйга чумып, бер ноктага текәлеп торса да, һаман җавап таба алмады. «Аурупа» нумирларының диварларындагы кандала оялары да, аның түшәме почмакларына матураеп бизәкләнгән үрмәкүч пәрәвезләре дә шул мәсьәләне хәл итә алмады. Кызган май берлән самавыр исе, иске тир исе берлән туглап ясаган коридордан кергән ис тә фикернең агуына, уеның бер тарафы җиңеп, бер ягы аста калынуына хезмәт итә алмады.

«Шул киемдә генә барса, әллә ничек илтифатсызлык иткән кеби күренмәсме икән?» — дип уйлады. Сюртуклар киеп китсә, бик үк рәсмиләшеп китеп, болай да ерак ике араны тагы ерагайтмасмы икән кеби булды. Тагы башыннан әллә нәрсә казынды. Иске гадәт белән ясалып куелган кагыйдәләр булмаганга, шундый әфәлем төрле өйләнүләрне гомерендә күрергә тугры килмәгәнгә, вакыт үткән саен, фикер чуала гына килде, хатын-кыз янына барганда киенмәенчә, төзәнмәенчә бару, әлбәттә, аларны эшкә салмау була. Хатыннарга ул начар хис калдыра, аларны мыскыл итә. Арттырып җибәреп, гадәттән тыш китеп бизәнеп йөрү ирләрне ваксыта, җитди түгеллекне күрсәтә.

Йә, ни эшлим?

Уйлаган саен вакыт үткәнгә, Хәмит, озак тормаенча, җуынып ташлап, костюм киде. Киеменә муафиграк муен бавы такты. Көзгегә барып басты. Якасы әллә нигә биегрәк тора. Аны алып ташлап, тәбәнәгрәк бер яканы эләктерде. Муен бавын яңадан бәйләде. Әллә ни булды, әллә нәрсәсе җитмәгән кеби күренде. Бер әйләнде, ике әйләнде. Күңелендәге әллә кай җире җитмәде, дигән уй эчен пошыруын киметмәде. Ул тагы бик җентекләп көзгедән тикшерергә кереште. Муен бавы артыннан чыгыбрак тора...

Жилетка төймәсе янында бер табы шактый акаеп тора... Чалбарының тезе дә бигүк туры түгел... Юк, булмады, ахрысы сюртук кимәенчә ярамый... Киенгәннән тиз иттереп тишенеп ыргытты. Кызулап-кызулап сюртук киенергә тотынды. Жилеткасындагы бер төймәнең «төшәм, төшәм» дип, селкенеп торуы тагы күңелгә тулмады, вакыт бик җиткәнгә, төймәне Аллага тапшырып, киенеп бетте. Көзге алдына барып басты. Адвокат кеби бер кеше...

— Кая соң ул кадәр кылынып барам? Шул чаналар, арба көпчәкләре, үзе чыгарткан дегет, күмер берлән сату итүче Садыйк Вахидичның кызы бар, имеш тә. Шуңарга ярар өченме? Тукта әле бу соң ахмаклык түгелме? Әй, көләргә кеше булса?..

Бердән Хәмит ике булды. Берсе әнә көзге алдында киенеп басып тора. Берсе почмакка баскан да, мыек астыннан көлеп тора.

«Карасана шул егеткә! Гакыллы да иде ләбаса. Кеше белән сөйли белә, һәр эшне уйлый белә иде ләбаса. Карасана, кәмиткә чыгарга хәзерләнгән курчакмыни?»

«Әй, ул эшчән әфәндем, үзенең тормыш иптәшен эзләргә килгән. Шунда, әнә теге урамда, ат тиреләре, сыер түшләре, куй майлары арасында үскән Нәфисә туташны да тапкан. Хәзер ул, шул асыл кызны үзенең матурлыгы, егетлеге, ирлеге берлән сихерләргә бара. Шуннан соң, Йосыф белән Зөләйхадагы кеби, Таһир белән Зөһрәдәге кеби, Ләйлә берлән Мәҗнүндәге кеби, Ромео белән Жульеттагы кеби, мәхәббәт, гыйшык башлана. Әй җүләр! Соң син әле ул кызның аксак түгел икәнен кайдан беләсең, син соң әле аның ит кисәге түгеллеген кайдан беләсең? Менә җүләр, менә тиле».

Ул кычкырып көлеп җибәрде. Көзгедәге үзенең күзләр кысылды, авызы киңәйде. Өстендәге сюртугы сикергәләде, бөкләнде. Ул кычкырып-кычкырып буылып теге җүләрдән көлде. Бердән күңеленнән салкын бер агым үтте. Теге җүләр, шәһәрдән шәһәргә йөреп сюртуклар киеп, ясанып-бизәнеп кыз алырга, фамилия сәгадәте корырга теләүче җүләр үзе Хәмит әфәнде шундый ахмаклыктан авыз тутырып көлә торган Хәмит әфәнде икәнлеге күңеленә төште. Аны бер куркумы, оялумы, хурланумы, үзеннән үзе җирәнүме хисе басты.

Ул: «Китәм, шул җүләрлекне бетерим»,—дигән фикергә килде.

Шуннан соң: «Җә, шул җүләрлекне тагы бер мәртәбә эшләмәенчә буламы соң? Табигый гына итеп өйләнеп китеп буламы соң?.. Ник булмасын, була... Мәсәлән, кем белән?.. Сөаль килеп җитмәде. Мария Ивановна күз алдына килеп басты. Әйе, аның белән көчләнеп сюртук киелми?.. Азапланып кирәкмәгән сүз дә сөйләнми? Һәммәсе дә табигый гына, үз юлыннан бара да чыга... Әй шул Мария Ивановна... Мәрьям Әхмәт кызы булсачы?.. Әле шул теге мишәр кызы, әллә ни булып, шәһәргә килеп чыксачы?.. Мин бу ахмаклыктан котылып калып, җүләрләнеп, кеше көлкесе булып йөремәсәмче? Әйе, Мария Ивановна бар... Күңелендә әллә нәрсә әрнеде, бер җире сыкрады, әллә нинди бер почмагы рәнҗеде, җылады. Әйе, әйе, яисә табигый иттереп

маржага өйләнү, яисә шулай ахмакланып, җүләрләнеп, бөтен мантыйксызлыкларны кылып, шул эшләрне эшләп йөрү... Башка юл юк, әйе, шулай эшләргә тиеш. Бүген шул кылынуларны көчләнеп булса да кылырга тиеш. Мин шуны эшләргә мәҗбүр. Яшь вакытымда сөю-сөешү дәверләрендә гакыллы булган булып авыз күтәреп йөрегәннең кәффарәтен түәр өчен. Хәзер шул ахмаклыкны кылырга мәҗбүр. Әйе, барам. Сюртук киеп барам. Кызы аз гына кеше төсле булса, аз гына иптәш итәргә өмет күренсә, тотам да кулын сорыйм. Әйе, мин шуны аңлап эшлим.

Ишек шакыды. Хәмит: «Боерыңыз»,— дигәнгә, Нәфисәнең агасы ишектән кереп: «Сез хәзерме,— диде,— ат белән килдем»,— диде.

Хәмит тә киемнәрен киенеп, ишеккә килеп ниткәндә, уң аягы белән чыгарга тугры килсен дип, адымнарын ваклап атлап, ишектән чыкты.

***

Озын өстәлнең ике башында да әллә никадәр эчемлек шешәләре эчләрендәге кызыл, ак, саргылт төсләре белән, шешәләрнең төрле-төрле хәҗемдәге кыяфәтләре белән ашъяулыкны төрлеләндереп торалар. Алар янына тезелгән озынча бокаллар, кечкенәле-зурлы рюмкалар, эчләренә төрле төстә эчемлекләр тутырылган графиналар аш янында ярышып торалар. Ике башта да, як-яннарда, калай савытларда серкәләнгән сардинка, кефаль, шпрот балыклары җәелеп алынганнар. Тозлы кыяр, тозлы кәбестә янына тураган тозлы карбыз өелеп куелган. Тозлы алмалар, ике якта да тәрилкәләреннән ташып, зур чүмәлә кеби утыралар. Читтә генә бер өстәлдә, поднос өстенә стаканнар куелып, ун-унбиш бутылка сыра да хәзерләнгән. Караңгы яңа гына төшеп килсә дә, өйгә бик күп лампалар ягылган. Ни өчендер, баягы китаплар этажеркасы өстенә җәйге хатын-кыз салам эшләпәсе китерелеп салынган. Хәмитне, Садыйкка башка, җуан гына, таза гына бер кеше дә каршы алды. Садыйк абзый утырышкач та, яңа кешегә карап:

Яңез, хәзрәт, бер дога,—диде. Вә догадан сон, «Бу менә безнең тирәнең ахуны була инде»,— диде. Ахун хәзрәт тә саулык, сәламәтлек сорашты,

шәһәрдәге мәктәп, мәдрәсә эшләрен сорады. Гәзитәләрдәге хәбәрләрне сорады, сөйләде. Гәзитә башындагы кешеләр хакында белеште. Кайберсе хакында үзенең танышлыгын белдерер өчен: «Фәлән вакытта, фәлән байда мәҗлестә, фәлән шәһәрдә җәмгыять эшендә мин аңарга шулай дигән идем, болай дигән идем»,— дип, үзенең шундый кешеләргә гакыл да бирмәй торган мулла түгел икәнлеген сиздерә килде.

— Без дә менә авылда мәктәп, мәдрәсә белән мәшгуль буламыз да, авыл халкы кара, сүз аңлатып булмый, земстводан менә көчкә генә акча алдырдым. Читкә дә чыга алмыймыз, менә шундый авылда ятамыз инде. Ни бит, авылга хезмәт итәргә кирәк, милләт ахрысы,— диде. Садыйк абзый да:

— Рәхмәт инде хәзрәткә, милләтне тәрәккый иттерергә бик тырыша. Мәктәбе, мәдрәсәсе, дисеңме. Әле белеш базардагы өен пивнойга биргән өчен, халык бит тиргәп йөреде. «Муллага килешми-фәлән»,— ди. Бер кызыл авызына: «Менә,— дидем,— пивной муллага фатир өчен өч йөз алтмыш тәңкә түли. Син бик дин кайгыртсаң, дүрт йөз бир дә ал»,—дидем.

Аш килде. «Утырыңыз, кунаклар!» — дип, Садыйк абзый хәзрәт белән Хәмитне утыртты. Үзе каршыларына утырып:

— Без инде, кунак, үзара гына булсын дип, чит кеше чакырмадык. Безнең монда кеше дә юк. Мулламыз шунда яңа дисәң, яңа түгел, иске дисәң, иске түгел. Мәҗлес күтәрми. Бик иркенләп кенә, озайтып кына утырыйк әле. Угылым, син мискиның калганын чыгар әле. Яңез, кунаклар! Берәрне аш алдыннан эчеп алыгыз әле. Ахун, сезгә үзеңезнекеме?

— Мин бик ул, хатыннар эчә торганы булмаса, сайламыйм.

Садыйк абзый: «Безгә мондый зыялы кешеләр берлән утырышу бик сирәк тугры килә, кадерен белергә кирәк. Сезгә, кунак?» Хәмит аптырабрак китте. Ни диергә кирәк, ул: «Рәхмәт, мин эчмим»,— дисә, мәҗлес әллә нindirәк булып китәр. Бу тәрәккый сатучы берлән милләтче ахун, әлбәттә, ак якалы Хәмитнең, сюртуклы Хәмитнең эчмәвенә ышанмыйлар. Үзенең шул мулла түгеллек хөрриятеннән шулай да файдалана белмәвенә инанмыйлар да, кәефләре дә китә. Эчим дисә, ул дөрестен әйткәндә, бу ахун хәзрәт берлән

Садыйк абзый аңлаган мәгънәдә эчми дә... Мәҗлес тугры килсә, кәеф күтәренке булса, халык шуны теләсә, берәрне, әлбәттә, эчәр иде. Ләкин монда ни эшләсен?...

Озак аптырап торырга ярамаганга:

— Миңа сыеграгын гына салыңыз,— диде. Садыйк аптырабрак карады:

— Ничек сыеграгын, актан дисезме? Хәмит:

— Йомшаграгын,— диде.

Сабырсызлык берлә Хәмитнен кыстатуын көтеп торган ахун, тәмам булгач та:

— Кадерле кунак хөрмәтенә,— диде дә чөмәлтеп җибәрде. Шул эчүе, торуы дәвам иткән кебек кенә вилка берлән балыкны алып капты. Шуны чәйнәргә тотынгач, әллә нигә тәме югалмасын дигән кеби, күзен кыса төште. Уртларын ялкау гына әйләндерде. Садыйк абзый зур гына ак рюмканы аударгач та, күзе ачылып китте. Әллә кай җиренә тормышка каршы елмаю, әллә кай җиренә шатлану килеп чыкты. Аның күзе ачылды. Нурланып: «Менә, әфәндем, тормышның мәгънәсен таптым»,— дигән кеби нурланып ачылды

Хәмит аз гына авызына алды. Телне чеметеп ала торган гына, баллы гына бер ачы ширбәт. Әллә кай бер җиреннән генә миләш исе дә килә. Су дисәң су түгел, куас дисәң, куас түгел... Лимонлы, шикәрле, тагы әллә ниле ширбәт. Бөгелеп киткәндә, әллә кай бер җиргә ачысы тиеп китте. Аның чырае сытылды. Ул тиз генә урыннан иң яхшы тора торган алманы алып капты.

Ул ара да булмады, Садыйк абзый тагы берәрне салды.

Хәмиткә карап:

— Сез бик аз эчкән икәнсез,— дип, анықын да тутырды. Тагы ахун хәзрәт берлән Садыйк абзый «алда торса, кадере китәр, йә очар» дигән кеби аударып алдылар. Хәмит тагы авызын чылатты. Озак кына иттереп шуның тамчыларын авызда йөртеп, моның нәрсә икәнен аңламакчы булды. Өченчедән соң ахун хәзрәтнең йөзенә көләчлек чыкты. Теле тишелде. Ул бертуктамаенча сөйләргә тотынды. Бишенчедән соң Садыйк абзыйның йөзенә бер карар чыкты. Аның төсеннән, йөзеннән сирәк кенә очрый торган мөлаемча

көлү, елмаю бөтенләй качты. Ул сугым суйганда, атны егып салып, чарлаган пычакны атның муенына китерә торган сугымчы кыяфәтенә керде.

Хәмит анын йөзендәге, битендәге шул ныклыкның таралганын карап:

— Бу, шул, теге боярлар берлән эчкәндә дә шул кыяфәт берлән эш итә торган, шул кансызлык белән алар белән мөгалләмә итә торгандыр,—диде.

Анын кан качкан йөзен, оят-тартыну качкан йөрәген Хәмит күргән кеби булды.

Анын тирән күзләре берлән үзен сөзгәнен күреп калтырап китте. Үзен-үзе корбанга сайлана торган тәкәләр кеби, үзен-үзе теге урмандагы пәри карчыгына әсир төшкәч ярыктан бармагын каптырып карый торган хан кызы кеби хис итте. Тәненә әллә нинди җирәнү, курку, хурланудан мөрәккәб хис йөгерде. Әллә кай җире пошынды. Әллә нинди җире сыкрады, күңеле рәнҗеде. Әллә нәрсәсе хурланды.

Ахун милләтнең тәрәкъкый итмәвеннән зарланды. Мәктәп, мәдрәсә хакында иң кызыл фикерләрне сөйләде. Милләткә манигы тәрәкъкый булган иске муллаларны тетте.

Хәмитнең йөзендә Садыйк абзый бертөрле сабырсызлык күрдеме:

— Ахун, ашка башлыйк,—диде. Үзе мискины ачып, угылына салырга кушты. Ахун аш алдыннан тагы берәрне чөмереп, ашка кереште.

Хәмит вак кына, тәмле генә пилмәннәрне ашый башлагач та, тирә-юньдәге тәэсирдән бераз котылды. Садыйк абзыйның йөзенә әллә нинди бер көләчлек, кунак сыйлауны яратудан килгән хуҗалык көләчлеге булырга кирәк, мөлаемлык чыкты. Ахун да пилмән тәме берлән милләтнең кара буяуларын онытты. Бәлештән сон бик күп җимешле, изрәгән ярмалы, өстендә мае агып йөри торган пылау килде. Анын артыннан куй маенда кызды-рылган осетра балыгы бирелде.

Хәмит никадәр куй маенын сасысын бетерергә тырышса да, табындагы лимунны алып, сыгып-сыгып юарга тырышса да, эштән чыгарылган балык ашарлык булмады.

Балык артыннан кыздырылган ит килде. Аннан соң, дөге бәлешеннән соң чапкан кәтлит, аннан соң каз ите, аннан соң желе, иң ахырдан зур бер торт мәйданга чыкты... Мәҗлеснең ахырына таба ахунның телләре бәйләнә, күзе кысыла башлады.

Дога кылып, аш кайтаргач, ул йомшак диванга утырып, чәй көткәндә изрәп тә китте.

Угылы мәҗлесне җыештырганда, Садыйк абзый Хәмитне үзенең конторасы янына утыртып, бәгъзе киңәшләр сорарга тотынды.

Өстәленең тартмасыннан шактый күп ренталар вә башка кыйммәтле кәгазьләр чыгарып, боларның базары ничек, боларның төшү ихтималы юкмы, дип, берәм-берәм мәгълүмат сорады. Ахырдан әллә никадәр испол-нительный листлар, вексельләр чыгарып, аларның да зурраклары хакында киңәшләр сорады, шуларның һәммәсе хакында:

— Аллага шөкер, эшләр бар, ләкин менә өлгереп булмый. Угылым яшьрәк, йомшаграк. Безнең эштә тимернең кызуында сугарга кирәк. Ауның капканга эләккәнен җибәрмәскә кирәк,—диде.

Чәй янында Садыйк абзый шәһәрдәге бер йортны сорашып утырды.

Ахырдан: «Менә безгә шул йортны алырга кушалар, бездә азрак залогы да бар иде. Нindirәк булыр икән? Шәһәрдә шул безнең кешемез юк. Ят кеше аркылы эш итү авыррак була»,—диде. Сөйләшмәенчә, кызулап-кызулап чәй чөмерә торган ахун хәзрәтнең теле ачылды.

— Садыйк әфәнде, әлхәмделиллаһ, байлыгыңыз бар, булдыклы гына кешегә дәүләтенә-ниенә карамаенча Нәфисә туташны бирергә кирәк тә, шунда йортын, йирен дә карарлар. Бара-килә йөрергә өй дә булыр,— диде. Үзе күзенең бер почмагы берлән «әмма шәп эшләдем бит» дигән кеби, Хәмиткә карады.

Чәйдән соң Хәмит, тагы Нәфисәне күреп булмауга пошыныбрак, сәгатьләренә карап, рәхмәт укып, чыгарга хәзерләнде. Садыйк:

— Угылым, угылым! Кунакны декаданска алып барыңыз. Безнең ахун берлән урман эшемез бар әле,— диде. Хәмитнең «рәхмәт» диюенә каршы:

— Барыңыз, ул бик яхшы электрик театры, Мәскәүдән килгән,— диде.

Хәмит күрешеп чыкканда, ишек төбендә ике чанада атлар җигүле иде. Егет Хәмитне утыртканның соңында, кучерга: «Син теге айгырга утыр, мин үзем тотармын,— диде,— Сәмигулла берлән кызлар куркыр,— диде.

Хәмит утырганның соңында артта ыштыр-шыштыр тавышлар чыкты. Егет әллә ни көтеп торса да, кучер:

— Абыстай, алдан чыгып китсеннәр, кызлар арттан күрә-күрә генә барырлар, вокзалдан әйләнеп барсыннар дип әйтәдер,—диде.

Шул әмердән соң егет атны сугып алдырып китте. Бер борылганда Хәмит шактый гына артта ике хатынның да килгәнен күрде.

***

Декадансның ложасына кергәч егет чыгып китте. Хәмит тыныч кына уйнала торган көй астында кечкенә генә залны, тезелеп утырылган халыкны күздән үткәрде. Шул күгелҗемрәк кәгазь ябыштырылган залда йоклар-йокламае кына иренеп кенә утырып картина көтә торган халык аралары машинадан чыга торган тонык кына көй арасында әллә нинди үзлек, туганлык, берлек балкып тора. Залның кәгазе каралганрак урынга ачык материядән кием кигән марҗа утырган. Көйнең бертөрлелеген, ялкаулыгын залның зур кәндилләре ялтыравы берлән тутырган. Утырган халык һәммәсе дә бер өйдән, бер гаиләдән, бер нәселдән чыккан дип белерсең. Хатыннарның барысынын да аз гына ачылган аякларында танга төсле оек ыржаеп тора. Ирләрнең каракүл якалары, кара мәче бүрекләре, бер калыптан кеби, җемелдәп тора. Утырышлары, кылынышлары, берсенә берсе карашлары да һәммәсенеке бер хәҗемдә. Кергән бер кеше ян-якка башын ия. Аңарга каршы залның бөтен тарафыннан чыраен сытыбрак, елмаебрак, ыржаебрак, җаваплар китә. Ятрак бер кеше кердеме, хатыннар күршеләре берлән колактан колакка пышылдашалар. Ирләре югарыга караган булып кына алындагы сафка кемлеген, кайданлыгы хакында хәбәрләр җибәрәләр. Хатыннар тәрҗемәи хәленнән бер кисәк кушалар. Өйләнгән, өйләнмәгән, ни өчен килгәнлеге

хакында уйдырмалар сибеләләр. Хәмитнең залга, ложага керүе һәм дә Садыйк угылы берлән керүе әллә никадәр хәрәкәт уятты. Колактан колакка сүзләр, Хәмиткә таба бөтен почмактан карашлар китте. Җуан гына бер марҗа лорнет белән озын гына сөзде. Бер приказчик кесәсеннән бинокль алды да күрше марҗаларына бирде. Хәмит ни диергә дә аптырап торганда, мелт итеп ут сүнде. Машина дер-дер-дер-дер иттереп сугыш маршын уйнарга кереште. Озын гына иттереп «брр» иттереп торганның соңында экранда солдатлар үтә башладылар. Ложаның ишеге ачылды. Берсе артлы берсе ике кыз, алардан соң теге егет килеп керде. Хәмит урыныннан торырга өлгермәде, кызларның берсе «Исәнмесез?» — дип кулын сузды. Хәмит икенчесе берлән күрешергә түгел икәнен сизенеп:

— Утырыңыз,— диде. Нәфисә акыртын гына утырды. Бер генә лампа яктысында, аның төсе моң гына, тонык кына күренде. Яныннан килә торган төрле ислемай исе бердән язгы печәнне хәтерләтте. Бердән бер кура җиләкне искә төшерде. Бердән җуан марҗалар яныннан үткәндә борынны ярып керә торган үткен бер ис борынны ярды. Хәмит бер мәртәбә караганның соңында:

— Исәнмесез, сәламәт торасызмы? — диде. Нәфисә акыртын гына тавыш чыгарып көлде дә бер сүз дә дәшмәде. Ул аптырап күзен ложага борды. Арттагы урындыкка утырган кыз тагы йөзен читкә алды. Хәмит гөнаһлы бер эш эшләгән икәнен сизенеп, экранга күзен атты. Анда солдатлар хәзер үтеп бетеп баралар. Алар артыннан ак атлы генерал берлән атлы гаскәр кереп киләләр иде Хәмит шул кадерле минуттан файдаланып, шул мәңгелек иптәшен тиз генә танып бетерер өчен, секунд та кадерле вакытны әрәм итмәс өчен:

— Сез кинематографка еш киләсезме? — диде. Нәфисә ни дип җавап бирсә мәслихәтрәк булыр икән дип, төшенеп торуы булырга кирәк, бераз тынганнан соң:

— Юк, әтиләр берлән генә киләм,— диде.

— Моннан соң театр бармы?..

— Юк... Яңа елда гына маскарад була...

— Татар театры сезнең шәһәргә килгәне бармы?..

— Артистлар килгән иде. Йөрделәр, йөрделәр дә, куя алмаенча киттеләр.

— Сез татар театрын күргәнеңез бармы?

— Бар. Мин шәһәрдә абыйларда кунакта торганда җизниләр белән барган идек. «Безнең шәһәрнең серләре»н куйдылар...

— Соң татар театрын яраттыңызмы?

— Яраттым. Бик күңелле булды. Аннан сон артисткалар биеделәр.

— Сез биемәдеңезмени?

— Юк, юк. Мин ни эшләп бийим.

Нәфисә туташ шул көлке сөальдән үзен тыя алмаенча көлде. Тонык кына яктыда, аның вак кына, ак кына тешләре матураеп күренеп китте. Экранда ут бердән сүнде. Картина алышты. Өч пәрдәдәге «Алданылган ир» исемдәге дәһшәтле драма күренә башлады. Нәфисә дикъкать берлән картинаны карый башлады.

— Сез кинематографны яратасызмы?

— Яратам. Менә боларның драмалары бик авыр була. Бик гыйбрәтле. Менә бер көн әле берсен куйганнар иде. Бер хатынны ире ташлап китә. Ул һаман сабыр итә. Ярлылана, акчасы бетә. Тегеңәргә хатлар яза. Жавап та юк. Ул әллә кая, чит җирдә, әллә нинди хатыннар белән йөри. Менә, парахутка матрос булып диңгезгә чыга. Парахут төнлә белән яр кырыена бәрелә дә бата. Менә бу матрос та бата. Шуннан яр буендагы кешеләр коткарырга китәләр. Бер көймә берлән теге хатын да китә. Ул да бер бата торган кешене өстерәп чыга. Ул аның ире була.Ул озак авырый. Терелгәч кенә тегенең хатыны икәнен белә. Шуннан тәүбә кыла. Бөтен халык җылады.

— Сез дә җыладыгызмы?

— Җыладым. Бик кызганыч бит.

Картинада алданылган ирне, үзенең дустлар, докторлар димләп-димләп, даруланырга һава алырга йибәрәләр. Бик кайгырган булып озаталар. Уен-көлке башлыйлар.

Хәмит сүзне алыштырырга уйлады.

— Сез өйдә ничек вакыт үткәрәсез, туташ? Нәфисә аптырап калды... Бер-бер хәйләле сөаль булмасын дигән кеби уйлаганның соңында:

— Өйләр җыештырам... Аннары... абый берлән шәһәргә чыгып керәм... Хәзер бит көн кыска. Үтә дә китә.

— Бернәрсә укыйсызмы?

— Укыйм. Мин ике ел марҗадан русча укыдым. Хәзер инде ташладым.

— Татарча нинди китаплар укыйсыз?

— Һәммәсен укыйм.

— Алай да, кемнәрнең әсәрләрен яратып укыйсыз? Нәфисә аптырауга калды. Кемнәрнекен икән соң?

Хәмит ярдәмгә килер өчен:

— Шигырьне яратамсыз, әллә нәсернеме?

— Икесен дә яратам...

— Тукайның шигырьләрен укыганыңыз бармы?

— Бар. Ник булмасын. Укыдым.

— Кайсы шигырьләрен яраттыңыз?

— Һәммәсен яраттым.

— Тагы кемнәрнең шигырьләрен сөеп укыйсыз?

Нәфисә тагы аптырабрак калды. Кемнәрнең шигырьләрен соң? Тел очында гына тора, әйтеп булмый. Ә тапты.

— Мәҗит Гафуриныкын...

— Әһе...

— Татар театрында бер генә булдыңызмыни?

— Бер генә булдым. Казанда кызык диләр. Һәр атнада яңа театр булып торадыр, ди. Безнең әни, мөселман теш докторы бар, дип газетада укыгач, барырга булган иде дә, әллә нигә калды...

Экранда әллә нәрсә чыж-пыж килде. Бер караңгыланды, бер яктырды. Хәмит шул кызга имтихан ясап утырганын сизеп үзенә-үзе ачуы килде. Кызга да күңелле булсын өчен, җинелчәрәк бер сүз башламакчы булды. Ләкин ни тугрысында сөйләсен?.. Һаваның суыклыгы, җәйнең матурлыгы хакындамы?

Болар бит һәммәсе дә шул Идел Әстерхан диңгезенә агадыр, дип фәлсәфә сатуга башка түгел. Хәмит юл таба алмады. Бердән зал ялтырап китте. Шуның кинәттән ялтыраулары күзләрне камаштырганга карамаенча, ул Нәфисә туташка күзен салды. Тәмам кыз. Бөтен әгъзасы урынында. Кечкенә генә чәчен бөрмәләндереп калфак кигән... Якты төстә, оста гына тегелгән кофта. Карасу көмешле җирлек өстеннән зәңгәр сыман юллар йөгереп-йөгереп төшкән юбка... Аягында, ни өчендер, җәйге сары башмак. Аның ябылып җитмәгән җирләрендә тупас кына, таза гына, өйдә эшләнгән кара оек ыржаеп тора...

Нәфисә Хәмитнең җентекләп караганын сизендеме, болай гынамы, шәлләрен яба төште. Кулларын яшеребрәк куйды.

Утыруны уңайрак итәр өчен булырга кирәк, яртылый торып, Хәмиткә яртылый арты белән әйләнде.

Хәмит, бер-бер уңайсызлык ясадыммы әллә дип, тирә-юньнән җавап көтәр өчен, тагы тирә-юньне сөзде. Артындагы кызның күзе-күзгә очрашкач, тулы гына, дорфа гына кыз:

— Әһе,— дип, көлеп җибәреп, яшергән булып шәл ярыкларыннан карарга тотынды. Нәфисәне болай ялгыз калдыру уңайсыз булыр, нәзакәтсезлек кеби тоелмасын өчен, Нәфисәгә борылды. Аны да кыйгачлап кына озын карап торган вакытта очратты.

Хәмит: «Әллә чыгып керикме, туташ?» — диде.

Нәфисә кызулап-кызулап: «Юк, юк, кирәкмәс... Әле дә әле әнә мөәззиннәр бөтен җәмәгатьләре берлән күзләргә килгәннәр»,—диде.

Хәмит зур гөнаһлы эш эшләгән кеби, кайгырырга да, кайгырмаска белмәенчә калды. Үзен үзе шул ахмак рольдән чыгарыр өчен, егеткә борылып, шундагы кешеләрне сораша башлады.

— Әнә теге, кыска казаки өстеннән сәгать чылбыры салындырган кеше, кем ул?

— Ул безнен шәһәрнең галантерея берлән сату итүчесе, әнә тегесе аның хатыны...

— Әнә теге, безгә таба бинокльләр берлән карый торган хатыннар кемнәр?

— Алар руслар. Мировой судья кызлары...

— Әнә теге мөгаллим сыман кеше кем?

— Ул безнең мөәззин угылы. Безнең әти аны мөгаллим ясамады да, шуның өчен безгә үчләнеп йөриләр...

Хәмит озак иттереп Нәфисәне ялгыз калдыру булмасын өчен тагы Нәфисәгә борылды.

— Сез, туташ, парахутта йөргәнегез бармы? — диде. Нәфисә теләмәгән тавыш берлән генә:

— Юк. Кая мин парахут берлән йөрим... Мин бит әти-әнисез бер җиргә дә барганым юк,—диде.

Хәмитнең эче поша башлады. Үзенең ахмак урыны, ахмак мөгамәләсе, иң тугрысы шул кызны сүзгә бәйләп җибәрерлек юл таба алмавы ачуын китерде.

Менә тагы пәрдә ачылды.

Яңа сүз башларга юлы ачылмаганга, Хәмит тә манзарәне карарга кереште.

Менә теге ир докторлардан даруланып йөри. Ул коена, компресс куя. Дарулар эчә... Хатынына сагынып хат яза... Үзенең бертөрлелеге, үзенең дорфа агышы, мәгънәсезлеге берлән бик тиз туйдырды. Ул ирнең ахмак мөгамәләләре аның эчен пошыра башлады. Аның мантыйксызлыгы саруын кайнатты.

Тагы үзенең өйләнергә, кыз карарга килгәнен хәтерләп, хәзер менә шул күршедәге кызның атасы-анасы моны яратканнан, каһарманлык ясап, кызларын аты-чабы чыгудан курыкмаенча, бергә кинематографка җибәрүләрен уйлап, үзенең шундый зур мәсьәлә берлән килгәнен төшенеп, тагы көчләнеп булса да, тагы Нәфисә берлән сөйләшергә кереште.

— Сәгыйтьнең хатыны Гайшә ханым сезнең кемегез була, туташ?

— Аның әнисе берлән безнең әнинең этиләре бертуган.

— Ерак кына икән.

— Шулай булса да, без алар белән якын булып йөрешеп торамыз... Гайшә апа җәйләрен безгә кунакка килә. Җизни дә елына берәр мәртәбә килеп китә...

— Алай икән. Иңде ни хакында?..

Тагы пәрдә өзелде, Хәмитнең «чыкмыйсызмы?» дигән сүзенә «юк» дип җавап алынгач, ул ялгыз чыгып китте. Пөхтә генә залда йөргәндә рус-татарының барсының да күзләре моңарга текәлде.

Дивардагы игъланнарны карап торганда, читтән бер кеше килеп, «Исәнмесез, кунак?» дип, бер генә кулын сузды. Хәмит «бу ни булды инде» дип кенә күрешеп, каравында дәвам итсә дә теге кеше:

— Исән йөримсез? Сез Садыйк абзыйларда кунактамыни? Сезнең белән бергә кызлары?.. Сез бик чибәр егет икәнсез. Алай-болай алданып куймаңыз. Мин әле мөселманлыктан гына әйтәм. Кызлары бик чая бит, бик үткен... Сезнең аның болай сабыр торуына карамаңыз... Пычактан да үткен инде, белмәгәне юк... Абзыйның соңгы сүзләре Хәмитне теләр-теләмәс көлдерде. Шул Нәфисәнең чаялыгы, үткенлеге, белмәгәне юклыгы аның эчен катырды. Ул тегенең сүзе тәмам булганны көтмәенчә, көлә-көлә борылып китте. Аңарга каршы килә торган мөгаллим сыманрак егет тагы берәр сүз сөйләмәсен дип, кырт итеп борылды. Тагы тегенең килүенә юл бирмәс өчен кызулап-кызулап ложага таба китте. Анда өч иптәшенең бик кызулап сөйләшеп утырган вакытларына очрап сүзләрен бүлдерде.

Акыртын гына кереп, урынына утырырга өлгермәде, тагы пәрдә ачылды. Хәмит бик ихлас белән манзарә карарга кереште. Нәфисә, әллә нәрсә, уңайсызлыкка очрадымы, урынында селкенде, борылды, Хәмит тарафына карады. Ни өчендер, Хәмит ягындагы сул кулының җиңнәрен күтәрә төшеп, кулына таянды. Терсәгенә кадәр ачылган кулы тонык кына яктыда матур, тулы төсле күренде. Аның төпкә табарак бөгелеп төшкән үрмә алтын беләзеге кулына матур бер шәүлә төшерде. Хәмит күз кырые берлән кечкенә генә, пөхтә

генә кулын тулып кына тора торган бармакларына кадәр карады. Шуны гына көткән кеби, Нәфисә кулын алды да куйды.

— Сез, туташ, музыка уйнамыйсызмы?

— Юк. Кечкенә чакта гармунда уйный идем. Хәзер онyттым инде. Сезгә теге мөәззин ни сөйләде? Сез аның сүзенә ышанмаңыз. Ул ялганлый. Ул безгә дошман.

— Әллә ниләр сөйләде шунда, мин, туташ, аның сүзенә әһәмият бирмәдем. Мин алай кеше сүзе берлән йөри торган кеше түгел...

— Алар ялганчылар. Алар яла ябалар,— диде.

Нәфисәнең йөзендә, күзендә ачулы бер ут уйнады.

Пәрдә төште. Халык кызу чыга башлады.

Хәмит сәгатен караганның соңында: «Әле вакыт иртә бит»,—дияргә өлгермәде, егет:

— Безгә чәй эчәргә кайтыйк,— диде.

— Рәхмәт инде. Хәзер соң булыр, менә монда буфет була. Шунда гына утырсак,— диде.

— Юк шул, алай булса, вокзалга барыйк,— диде.

— Ярыймы, Нәфисә туташ? — диде.

— Белмим, соң булмасмы? Әтиләр ачуланмасмы? Теге соң мөәззиннәр тагы әллә ниләр сөйләмәсме?

Хәмит:

— Мин иңде анысын белмим. Сезнең берлән бит бер дә рәтләп сөйләшеп булмады,— диде.

Нәфисә күзе берлән энесенә:

— Бар, киемнәрне китер, акыртын гына чыгармыз,— диде. Тиен эчле тунын Хәмит кидерергә теләсә дә,Нәфисә: «Юк, юк»,—дип, ложаның почмагына ук барып качты. Үзе бер шатланган, бер ачуланган кеби көлеп кулларын бутады.

Акыртын гына үз пальтәсен киеп, кызларның шәлләрен пөхтәләп кигәннәрен көтеп торды. Менә теге кыз тиз генә чыгып китте. Калушын

күтәреп, аның артыннан Нәфисә чыкты. Анда чыгарга ярамый дигән кеби егет ишек янына басты. Хәмит акыртын гына калушларын киде. Бер кулына перчаткасын киде. Акыртын гына чыкты. Бер-ике сажин алдыннан кызуланып-кызуланып кызлар баралар иде. Нәфисә, инсафлырак булыр өченме, башын ия төшкән. Шуңарга күрә аркасы чыга төшкән иде. Аяклар, кызу-кызу атлагангамы, чалышрак басылалар. Гәүдәсе әле бер якка, әле бер якка чүмәләп, чүкәләп бара иде.

Ишек төбендә атларга утырганда, алар янына тагы бер ике-өч татар килде. Шуларның баскан бүреклесендә Хәмит баягы мөгаллим сыман кешене таныды. Нәфисә шуларны күрдеме, кызулап-кызулап менеп утырып атка кузгалырга кушты. Хәмит берлән егет тә алар артыннан киттеләр. Тегеләрнең берсе:

— Хәерле юлга,—диде. Вә китапта языла алмый торган бер-ике җөмлә дә кушты.

Атлар, кошлар кеби очып, вокзалга барып иштеләр.

Аттан төшкәннең соңында, Нәфисә бер-ике мәртәбә артына борылып карады да, акыртын гына, икеләнеп, атлый башлады. Хәмит аның янына килеп:

— Сез шуларның сүзләрен дә илтифат иттенез. Юкка эчеңез поша,— диде. Нәфисә:

— Алар һрвакыт шулай. Ни булса да каршы төшәләр. Менә мин этигә әйтим әле. Мөфтигә хат язып, указын алдырсын әле,—диде. Хәмитнең күзе тагы Нәфисәнең гәүдәсенә, буена төште. Аннан атлавына, йөрүенә күчте.

Әнә ул бүксәсенә тутырган үрдәк кебегрәк чайкалып-чайкалып атлый. Хәмит баскычтан менгәндә, падручка алмакчы булды.

Нәфисә куркып читкә китте... Ул тагы, гөнаһ эшләгән кеби, артка калды. Менә залга керделәр. Караңгырак кына бер почмакка барып Нәфисә утырды. Аның артыннан теге кыз башын читкә борып кысылды, Хәмит:

— Киемнәренезне салмыймсыз, тирләмәссезме? — дисә дә: «Юк, юк» диештеләр. Хәмитнең «Ни эчәсез?» диюенә дә бер җавап та алынмады. Ул:

— Кофемы, шикаладмы, чәйме? — дигәч кенә, «кофе» диделәр. Менә барысына да кофе килде. Искергән пирожныйлар килде. Хәмит үзе буфетка барып бер савыт шикалад та алып килде. Кофены акыртын гына эчтеләр. Сүз тагы бәйләнмәде. Кырт-мырт кына сөйләгәннең соңында кызлар: «Кайтамыз, кайтамыз»,— диергә тотындылар. Вокзалдан чыккач, күрешкәндә Нәфисә Хәмитнең кулын озаграк тотты. Ул түбәннән генә карап:

— Гаеп итмәңез. Иртәгә дә рәхим итеңез, — диде. Хәмит кулын сузгач, теге кыз да өч бармагын гына төртте. Нумир төбенә җиткәч, теге егет:

— Иртәгә иртә чәйгә рәхим итегез, мин килеп алырмын. Сәгать ничәләрдә торасыз? — диде. Хәмит, рәхмәт әйтеп, нумирга кергәч тә озын иттереп бер сулады. Ишекне ябып куеп үзенең ялгызлыгынамы, үзенең әллә нинди танымаган, белмәгән кешеләр берлән, белмәгән, ишетмәгән телдә сөйләргә мәҗбүр булмавынамы, кәефе килде. Әллә тегеләй генә уңай булып киттеме. Ул рәхәтләнеп-рәхәтләнеп сулады. Аягын зур-зур атлап бүлмә буенда йөреде. Һичкемнән курыкмаенча, кулларын селкеде, бутады. Беркемгә дә илтифат итмәенчә көлде, сызгырды. Киемнәрен салып йокларга ятарга, зур йөкне ташлаган, бик авыр вакыйга үтәп бетергән кеби йокларга җыенды. Кылт итеп, иртәгә сигездә тору, иртә чәйгә, пәрәмәчкә барыр өчен тору дигән фикер килеп төште. Ул ятыр-ятмас, урыныннан торды. Әйе, иртәгә барырга... Әле соң бетмәдеме? Бүгенге бөтен манзарәләр аның күзеннән үтте. Һәммәсе авызда бер төчеле-әчеле тәм калдырып китте. Нәфисәнең бәжул исенә сөртенеп теге пивнойга йорт бирә торган мулла килеп басты. Уйсыз сүзләр әйтеп кала торган мөәззиннән хәер исе борынга бәрелде. Нәфисә ава-түнә, җәбәйләп-җәбәйләп басып, куй маена кыздырган балыкны алып килгән кеби булды.

Әллә нинди помада исе кушылды. Шуңарга кинематографтагы мәгънәсез манзарәләр, альбомдагы медальле үрәтникләр, симез битле Садыйк абзый үзе, Нәфисә кеби кечкенә генә, вак кына, кәкре генә анасы килеп сипләнде. Һәммәсеннән бергә имбир, балык мае исе чыккан кеби булды. Һава тарайды, сулыш кысылды. Бик күп итеп майлы тутырма ашаган кеби, махмырлау кикертүе авызга килде, сару кайнады.

Шул бүлмәдә тора алмаячагын, иртәгә барып шул комедияне, майлы пәрәмәч, коймаклар, пәрдәләр кушып дәвам иттерә алмавын хис итте дә, сикереп торып звонок бирде, кергән хезмәтчедән дүртенче класслы гына поезд бер сәгатьтән үтүен белгәч, тиз генә әйберләрне җыештырып төенләде. Кыска гына кәгазьгә Садыйк абзыйларга «Кадер-хөрмәтеңезгә рәхмәт», дип хат язып салып, йоклый-йоклый бара торган извозчикта вокзалга барып та җитте. Аның тонык утлары арасыннан үтеп, яртылый йоклый торган халык арасына дүртенче класска килеп кергәч тә, күкрәге иркенәеп китте.

Шул иркенлекне поезд бирде дип хис иттеме, эч күңеленнән «әле дә тимер юл бар», дип шатланып куйды.

Станцияләрдә озак туктавын да гафу итте. Вагондагы тыгызлык, уңайсызлык та, иртәгәге пәрәмәч мәҗлесеннән башланачак эч пошырудан коткаручы кеби хис ителде. Яртылый йоклый-йоклый ул шәһәргә юнәлде. Иртә берлән вагонга кергән сатучы кытайдан, матур бер ваза күргәч, «Мария Ивановнага бүләк булыр»,—дип, шуны да алды. Вазаны күтәреп, шәһәр урамы буеннан кайтып килгәндә, чәчәк кибетенә очрагач, шул вазага куярга чәчәк тә алып барыйммы, әллә анысын әле иртәгәме дип, икеләнә-икеләнә ул өенә таба борылды. Почмаклардагы театр игъланнары арасында бүген «Фауст» куелачагын күреп:

— Мария Ивановна билет ала алган булса ярар иде,— дип уйлана-уйлана баскычтан менде.

### Искәртмәләр һәм аңлатмалар:

*Замир* — эчке ягы, эчтәлеге.

*Мөзакәрә* — фикер алышу.

*Иттифак итешү* — бу урында: сүз куешу.

*Түги (тугой) аяклы* —авыр аяклы, саран.

*Тишеп* — чишеп.

*Мөрәккәб* — җыелган.

*Хөррияте шәхсия* — шәхси ирек.

*Бер никә* — бер нәрсә.

*Хасыйле* — кыскасы.

*Сәдидә* — тиз, тигез.

*Аталар* — утраулар.

*Кәшеф* — ачу.

*Икърар итү* — тану.

*Тәҗвид* — дөрес итеп әйтү.

*Хитам* — бетү, тәмам булу.

*Күкфарас* — купорос.

*Карт* — иске.

*Дәм* —ис.

*Иттифакый* — очраклы.

*Пәйнәр* — сыр.

*Исмасам* — ичмасам.

*Белемсез* — билгесез.

*Зиярәт* — күрешергә бару.

*Тәгъриф* — аңлату.

*Низам* — тәртип.

*Помада (помадка)* — йомшак кәнфитләр төре.

*Кушып* — кушылып.

*Мирас тарикы берлән* — мирас буенча.

*Мәсафә* — ике урын арасындагы ераклык.

*Визитка* — бу урында: кунакка барганда кия торган кием.

*Әфәлем төре* — төрле – төрле.

*Муафикъ* — яраклы, килешле.

*Фамилия сәгадәте* — гаилә бәхете.

*Кәффарәт* — бу урында: әҗер.

*Хәҗем* — күләм, зурлык, үлчәм.

*Тәрәкъкый* — алга китү, прогресс.

*Мөррәккәб* — ясалган, җыелган.

*Манигы тәрәкъкый* — яңалыкка каршы.

*Осетр(осетр)* — мәрсин балыгы.

Хәҗем — үлчәм.

**Ул икеләнә иде** — Хикәя беренче тапкыр «Ил» гәзитәсенең 1914 ел 19, 24, 31 декабрь (52, 54, 55) саннарында басылган. 1917 елда Казанда «Гасыр» китап нәшриятында «Мәгариф» типографиясендә аерым китап булып басылып чыга. Сигезтомлыкта: 8 нче җилд, 2 нче китап. 46 бит.

Текст 1917 елгы басмадан алынды.

*Балкан иттифакы* — 1912 елда Төркиягә һәм Австро-Вен- грияга каршы Болгария, Сербия, Греция һәм Черногория дәүләтләренең Россия ярдәме белән төзелгән хәрби-сәяси берлеге. Бу берлек 1913 елда таркала.

*Мисыр, Судан, Фас (Марокко)* — Африкадагы дәүләтләр.

*Албасты* — халык ышануларында: йоклаганда кешене саташтыра, баса торган җен, явыз рух.

*Әлиф яткан* — гарәп әлифбасындагы «а» хәрефе сурәтенчә, ягъни таяк шикелле төп-төз яткан.

*Тукай Габдулла* (1886—1913) — татар халык шагыйре.

*Пушкин Александр Сергеевич* (1799—1837) — рус шагыйре.

*Поляк, Литва мөселманнары* — биредә татарлар турында сүз бара. Тарихи документлар буенча, татарларның беренче чирүләре бу якларга ундүртенче гасырда ук килеп чыга. 1313 елда алар Литваның бөек кенәзе Гедиманаска немец тәре йөртүчеләрен кире кагарга ярдәм итәләр. 1397 елда татарлар бирегә күпләп күчеп киләләр. Сугышчан татар гаскәрләрен кенәз Витаутас үзенә ярдәмгә чакыра. Аларга җирләр бүлеп бирә, бөек дәрәҗәләр

өләшә. Татар чирүләре поляк-литва җирләрен күп бәлаләрдән саклый. Шәрекъ телен яхшы белгән татарлар Литва кенәзе һәм Польша короле сарайларында тәрҗемәчеләр булып та хезмәт итәләр.

Польша, Литва татарлары 1—2 гасыр эчендә телләрен оныталар, ләкин үзләрен татар дип атыйлар, ислам динен тоталар, ата-бабалары гореф-гадәтләрен саклыйлар. 1997 елда татарларның Польша, Литва җирләренә рәсми күчеп килүләренә 600 ел тулды.

Бөек Ватан сугышына кадәр Польшада поляк телендә поляк-литва татарларының тарихы, тормышы, мәдәнияте турында «Рочник татарски» («Татар елъязмасы») дигән исемдә өч җыентык чыгып өлгерә (1932 — Вильнода, 1935 — Замощчта, 1938 — Варшавада). 1932 елгы җыентыкта Г.Исхакый турында белешмә һәм аның «Польша татарларының милли мәсьәләләре» исемле мәкаләсе басылып чыга. Бу вакытта Г.Исхакый, Варшавада торып, Берлинда басыла торган «Милли юл» (соңыннан «Яңа милли юл») журналларын хәзерли. «Рочник татарски» дагы мәкаләсенә караганда, ул бирedәге милләттәшләре белән элемтәдә булган, татар зыялыларына әлеге җыентыкны хәзерләү һәм басып чыгару турында ул үзе үк тәкъдим иткән булырга мөмкин.

*Зәкъкум* — җәһәннәмдә гөнаһлылар ашый торган җимеш.

*Обод* — тәгәрмәчнең тышкы ягына куела торган kыршау, тугым.

*Коммивояжер* — сәүдә эшендә үрнәкләр буенча товар тәкъдим итеп йөрүче агент.

*Исмәгыйль бәк Гаспринский* (Исмәгыйль Мостафа улы Гаспралы, 1851—1914)—җәмәгать эшлеклесе, педагог, нашир һәм әдип.

*Ниязи бәк* (Габдрахман бине Нурмөхәммәд бине Мөхәммәднияз, 1880—1937) — күренекле ислам дине белгече, әдип. Ата-бабалары төрекмән Таифәсеннән булган, әмма Әстерханда гомер буе татар арасында яшәп, шул телдә иҗат иткәнгә, Ниязи үзен татар халкыннан аермаган. Әстерханда «Низамия» мәдрәсәсен тәмамлагач, шул ук «Низамия» мәдрәсәсендә

мөгаллим, 1908 елда «Идел» гәзитәсендә вакытлыча мөхәррир булып эшләгән. Галимнең билгеле булган, басылган хезмәтләре арасында «Дивани Мәхтүм Колый», «Хотбәләр мәҗмугасы» кебек китапларын атарга мөмкин.

*Дума* — патша Россиясендә һәм Мәскәү Русенда: идарә учреждениеләренең исеме (Дәүләт думасы — 1905—1907 еллардагы революция барышында төзелгән вәкиллекле, формаль яктан закон чыгару функцияләре булган учреждение.

*Родзянко Михаил Владимирович* (1859—1924) эре алпавыт, октябрист, III, IV Дәүләт думасы рәисе. Октябрь революциясеннән соң чит илгә китә, «Империянең жимерелүе» дигән истәлекләре басылып чыга.

*Исправник* — Русиядә өяз полициясенең башлыгы. 1775— 1802 елларда дворяннар сайлаган, аннан соң хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән.

*«Зиләйлүк»* — борынгы татар халык көе.

*Бурка* — тукымадан сырып тегелгән яки киез кунычлы, күн табанлы аяк киеме.

*Җөббә* — жиләннең бер төре.

*Таһир белән Зөһрә* — XIX йөз татар шагыйре Әхмәт Курма- ши-Уразаевның «Таһир илә Зөһрә кыйссасы» (Казан, 1882) әсәренең геройлары.

*Ләйлә белән Мәҗнүн* —XII йөз азәрбәйҗан шагыйре Низами Ганҗәвинең «Ләйлә вә Мәжнүн» поэмасы геройлары.

*Ромео белән Жульетта* — инглиз драматургы һәм шагыйре Уильям Шекспирның «Ромео и Джульетта» пьесасы геройлары. Рента —капиталистик илләрдә облигацияләре булган кешеләргә даими доход китереп тора торган сроксыз дәүләт заемы.

*Кәндил* — берничә шәм яки электр лампочкалары куела торган зур шәмдәл.

*Лорнет* — сапка утыртылган күзлек, саплы күзлек.

*«Безнең шәһәрнең серләре»* — татар драматургы Галиәсгар Камал (1879—1933) комедиясе.

*Мәҗит Гафури* (Габделмәжит Нургали улы, 1880—1934) — татар-башкорт язучысы, публицист.

*Мировой судья* — Англия, Франция, Америкада һәм революциягә кадәр Россиядә кешеләр арасындагы төрле бәхәсләрне һәм вак җинаять эшләрен тикшереп хәл итүче судья.

*Бажҗул* — хушбуй.

*«Фауст»* — опера. Текстын немец язучысы Иоганн Вольфганг Гёте (1749—1832) язган, музыкасын француз композиторы Шарль Гуно (1818—1893) ижат иткән.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б.311-361.